ШИМБӘ
24 ФЕВРАЛЬ
1940 ел
№ 45 (5845)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—73, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

Партиянең район конференцияләре

Партиянең башлангыч оешмаларында отчет-сайлау җыелышлары гаять зур оешканлык, югары активлык белән үттеләр. Отчет-сайлау җыелышларында коммунистларның төп игтибары—партиябезнең тарихи XVIII нче съезды карарларын үтәү өчен башлангыч партоешмаларның ничек көрәшүләрен тикшерүгә, эштә булган җитешсезлекләрне ачуга һәм аларны тәнкыйтьләүгә, партиянең җитәкче органнарына Ленин—Сталин партиясенә чын күңелдән бирелгән кадрларны сайлауга, партия демократиясен киң җәелдерүгә юнәлдерелде.

Менә Казан шәһәрендәге Киров районының башлангыч партоешмаларындагы кайбер йомгаклар. Отчет-сайлау җыелышлары булып үткән оешмаларның 38 ендә партия членнары һәм кандидатлары 1.789 кеше хисаплана, шулардан 1.661 кеше отчет-сайлау җыелышларында катнашкан. Докладлар буенча фикер алышуларга катнашу өчен барлыгы 344 кеше язылган һәм шулардан 317 кеше чыгыш ясаган. 38 башлангыч партоешманың 31 ендә эш канәгатьләнерлек, 7 сендә канәгатьләнмәслек дип табылган. Бу хәл үткән чор эчендә башлангыч партоешмаларның гаять зур күпчелеге үзләренең алларына куелган бурычларны яхшы аңлаганлыгын һәм аларны үтәү өчен большевикларча көрәшкәнлеген ачык күрсәтә.

Парторганнарны сайлауга коммунистлар җидди карадылар, җитәкче органнарга партия эшенә чын күңелдән бирелгән кешеләрне сайлауга гаять зур игтибар бирделәр. Моны шул ук районның 37 башлангыч партоешмасында үткәрелгән сайлаулар бик ачык раслыйлар.

Башлангыч оешмаларның партбюролары һәм секретарьлары составына сайлау өчен барлыгы 154 кандидатура күрсәтелә һәм шул кандидатлар буенча 172 кеше чыгып сөйли, тикшерүләр аркасында сайлау бюллетененә кертү өчен 130 кандидатура калдырыла. Ябык-яшерен сайлау нәтиҗәсендә 96 кеше сайлана.

Шунсы характерлы: 37 оешманың 22 сендә секретарь итеп элекке составта секретарь булып эшләгән иптәшләр сайланганнар, партбюро членнары һәм башлангыч оешмаларның секретарьлары итеп сайланган 96 иптәшнең 50 се яңа кадрлар. Бу фактлар, беренчедән, безнең башлангыч партоешмаларыбызның секретарьларының гаять зур күпчелеге нык һәм үзләренә йөкләнгән бурычларны үтәүгә сәләтле икәнлекне күрсәтсә, икенчедән соңгы ике ел эчендә талантлы, чыныккан яңа кадрларның никадәр тиз үскәнлекләрен күрсәтә.

ВКП(б) райкомнары тарафыннан отчет-сайлау җыелышларына җитәкчелек кирәгенчә булмаган урыннарда сайлау вакытларында төрле ялгышлар җибәрүгә юл кую фактлары да булганлыгын әйтеп үтәргә кирәк. Мәсәлән, отчет доклады буенча карар кабул ителми торып, сайлауларны үткәрү (Теләче райкомы янындагы башлангыч оешма), ВКП(б) район конференциясенә делегат итеп ВКП(б) членлыгына кандидат булган кешеләрне сайлау (Мамадыш районының Уполнаркомзаг янындагы башлангыч оешма) кебек фактлар булды. Мондый җитешсезлекләр бары тик сайлау эшенә игтибарсыз карау нәтиҗәсендә килеп чыкканнар.

Хәзер партия оешмалары отчет-сайлау кампаниясенең икенче җаваплы чорына керәләр. 25 нче февральдән партиянең район конференцияләре башлана. Бу конференцияләрдә коммунистлар партиянең XVIII нче съезды тарафыннан куелган политик, хуҗалык һәм культура бурычларын ВКП(б) райкомнарының ничек үтәгәнлекләрен һәм шул бурычларны үтәүгә партияле һәм партиясез массаларны ничек туплаганлыкларын тикшерәчәкләр.

Отчет чоры эчендә партиябезнең район оешмалары алдынгы эшчеләр, колхозчылар һәм интеллигентлар хисабына үсте, партияле һәм партиясез кадрларыбызны марксизм-ленинизм таглиматы белән коралландыру буенча, яңа, яшь кадрларны тәрбияләү һәм җаваплы эшләргә күтәрү буенча күп кенә эшләр башкардылар. Ләкин әле бу безнең эшебездә җитешсезлекләр юк дигән сүз түгел. Алар, һичшиксез, бар әле.

Партиянең район конференцияләре алдында гаять бөек бурычлар тора. Конференцияләрдә катнашучы делегатлар үткән вакыт эчендә ирешелгән уңышларны күрсәтү белән бергә, эштә булган кимчелекләрне кискен рәвештә, большевикларча тәнкыйть итәргә, тагын да зур адымнар белән алга хәрәкәт итү юлларын күрсәтергә тиешләр. Район конференцияләренең төп игтибары партия эшенең тагын да күтәрелүенә, аерым алганда пропаганда һәм агитация эшен тагын да яхшыртуга, яңа кадрларны тагын да кискенрәк күтәрүгә, аларга булышлыкны көчәйтүгә, партияле һәм партиясез кадрларны тәрбияләүне барлык чаралар белән ныгытуга юнәлдерелсен. Дәүләт планнарын үтәү һәм арттырып үтәү Сталинчыл югары иген уңышы өчен, язгы чәчүгә большевистик хәзерлекне тиз арада төгәлләү өчен көрәшкә партияле һәм партиясез большевикларны туплау игтибар үзәгендә торырга тиеш.

Без икенче империалистик сугыш җәелгәннән-җәелә барган обстановкада эшлибез. Империалистлар төрле юллар белән безнең илебезне сугышка тартмакчы булалар. Безнең дәүләтебез эзлекле рәвештә тынычлык политикасын үткәрә, ләкин шулай да империалистларның һәр төрле яңа авантюраларына каршы без һәр вакыт хәзер торырга тиешбез. Менә шуңа күрә дә партиянең район конференцияләре оборона эшен тагын да ныгыту мәсьәләсенә зур әһәмият бирергә тиешләр.

Партиянең һәрбер район комитеты алдында гаять зур политик һәм хуҗалык бурычлары тора. Менә шуңа күрә дә, район комитетлары составына Ленин—Сталин партиясе эше өчен ахрынача көрәшергә сәләтле, чын күңелдән бирелгән работникларны сайлау һәм кадрларны сайлап алу турында иптәш Сталин тарафыннан куелган принципны нык рәвештә һәм тулысынча тормышка ашыру район конференциясе делегатларының иң мөһим бурычларыннан берсе булып тора.

Һич шик юк, партиянең район конференцияләре партиянең район комитетлары составына иң яхшы кешеләрне сайлап, партия органнарын тагын да ныгытуны тәэмин итәрләр.

17 нче февральдә СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. И. Калинин бүләкләнүчеләргә орденнар һәм медальләр тапшырды. РӘСЕМДӘ (сулдан уңга): фин ак гвардеецларына каршы көрәш фронтында күрсәткән кыюлыклары һәм батырлыклары өчен бүләкләнүчеләрдән өлкән лейтенант В. Г. Белокринецкий, өлкән политрук Б. П. Степанов һәм майор Ф. П. Мотыйлев иптәшләр. А. Грибовский фотосы (ТАСС фотоклишесе).

ССР СОЮЗЫ ОРДЕННАРЫ ҺӘМ МЕДАЛЬЛӘРЕ ТАПШЫРУ

22 нче февральдә СССР Верховный Советы Президиумы Председателе иптәш М. И. Калинин бүләкләнүчеләргә орденнар һәм медальләр тапшырды.

Хөкүмәтнең сугыш заданиеләрен үрнәк булырлык итеп үтәгән һәм шул вакытта геройлык күрсәткән өчен лейтенант иптәш Н. В. Гриневка һәм өлкән лейтенант иптәш И. С. Мясниковка Советлар Союзы Герое исме бирелү турында грамота, Ленин ордены һәм „Алтын Йолдыз“ медале тапшырыла.

Хөкүмәтнең сугыш заданиеләрен үрнәк булырлык итеп үтәгән һәм шул вакытта батырлык һәм геройлык күрсәткән өчен Кызыл Армиянең бүләкләнгән сугышчыларына, командирларына һәм политработникларына орденнар һәм медальләр тапшырыла. Бүләкләнүчеләр арасында—2 нче ранг хәрби врач Д. И. Дроздов, лейтенант П. П. Божков, кече командир С. Н. Белохвостов, кызыл армеец Я. В. Веселов, политрук М. И. Гудков, лейтенант С. Я. Гукало һәм башка иптәшләр бар.

Аннары фин ак гвардеецларына каршы көрәш фронтында командованиенең сугыш заданиеләрен үрнәк булырлык итеп үтәгән һәм шул вакытта батырлык һәм геройлык күрсәткән өчен бүләкләнгән өлкән лейтенант И. М. Назаретский һәм А. Ф. Поляков иптәшләргә бүләкләр тапшырыла.

Бүләкләнүчеләр исеменнән Н. В. Гринев һәм М. И. Гудков иптәшләр чыгып сөйләделәр.

Шулай ук бүләкләнгән хәрби һәм хуҗалык работникларының башка группаларына да орденнар һәм медальләр тапшырыла.

Бүләкләнүчеләргә орденнар һәм медальләр тапшырганнан соң иптәш М. И. Калинин барлык иптәшләрне бүләкләр алу белән чын күңелдән котлады һәм киләчәк эштә аларның яңа уңышларга ирешүләрен теләде. (ТАСС).

Кызыл Армиянең XXII еллыгына багышланган тантаналы утырыш

22 нче февральдә Зур Театрда Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгына багышлап хезмәт ияләре депутатлары Казан Шәһәр Советы сессиясенең тантаналы утырышы булды. Зур күтәренкелек белән үткән бу утырышта партия, совет, комсомол һәм профсоюз активы, Казан гарнизонының командирлары, политработниклары һәм кызыл армеецләре катнашты.

Озак вакыт дәвам иткән көчле алкышлар астында почетлы президиумга ВКП(б) Үзәк Комитетының Политбюросы һәм иптәш Димитров сайлана. Ленин белән бергә Кызыл Армияне оештыручыны, Кызыл Армиянең бөек юлбашчысын һәм гениаль полководецын—иптәш Сталинны утырышта катнашучылар көчле алкышлар белән котлыйлар.

Утырышта Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының данлыклы XXII еллыгы турында иптәш Гринько доклад ясады. Докладтан соң көчле алкышлар белән Сталин, Молотов, Ворошилов иптәшләргә, Ленинград Хәрби Округының командирларына, политработникларына һәм кызыл армеецләренә котлау хатлары кабул ителә.

Җыелыштан соң, Зур Театр коллективы тарафыннан „Ленин“ исемле пьеса куелды.

БӨТЕНСОЮЗ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ КҮРГӘЗМӘСЕ БАШ КОМИТЕТЫНЫҢ 1940 НЧЫ ЕЛ, 20 НЧЕ ФЕВРАЛЬ КАРАРЫ

Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашучыларны—яхшы эш үрнәкләре күрсәткән колхоз председательләрен, машина-трактор станцияләре һәм совхозлар директорларын, авыл хуҗалыгы белгечләрен, алдынгыларын һәм оештыручыларын бүләкләргә.

ТАССР БУЕНЧА:

ЗУР АЛТЫН МЕДАЛЬ БЕЛӘН

1. Евдокия Григорьевна **Агафонованы.**
2. Анна Яковлевна **Барышеваны.**
3. Гобәйдулла Гани улы **Ганеевны.**
4. Рамазан Мөхәммәтгәрәй улы **Гәрәевне.**
5. Мөбарәкша Дәүләтша улы **Дәүләтшинны.**
6. Габделкадыйр Фәттах улы **Кәлимуллинны.**
7. Зәки Закир улы **Кәримовны.**
8. Гариф Гали улы **Манеевны.**
9. Василий Петрович **Мосоловны.**
10. Фәтхул Мөхәммәт улы **Мухәметшинны.**
11. Гафур Садри улы **Садреевны.**
12. Шәйрази Солтан улы **Солтановны.**
13. Мәрьям Латыйп кызы **Яппарованы.**

КЕЧЕ АЛТЫН МЕДАЛЬ БЕЛӘН

1. Мария Николаевна **Ахметкинаны.**
2. Анна Анисимовна **Васинаны.**
3. Хуҗа Галиулла улы **Галиуллинны.**
4. Галиаскәр Гәрәй улы **Гәрәевне.**
5. Клавдия Мироновна **Засоринаны.**
6. Артемий Николаевич **Киселевны.**
7. Даниил Иванович **Кузнецовны.**
8. Амир Майорович **Майоровны.**
9. Гомәр Габдулла улы **Мамашевны.**
10. Җиһанша Мөбарәкша улы **Мөбарәкшинны.**
11. Габделгата Нургата улы **Нургатинны.**
12. Аким Алексеевич **Пальчиковны.**
13. Сергей Дмитриевич **Покровскийны.**
14. Сәхап Фәйзи улы **Сәмитовны.**
15. Әкрәм Закир улы **Сафинны.**
16. Ирина Родионовна **Тимохинаны.**
17. Василий Павлович **Темниковны.**
18. Миңнемөхәммәт **Фазлеевны.**
19. Әхәт Сафи улы **Хәбибуллинны.**
20. Хәлиулла Хәйрулла улы **Хәйруллинны.**
21. Җиһанша Салах улы **Шихмуратовны.**
22. Разия **Юсуповаңы.**

(„Известия“ 23 февраль).

Анатоли агентлыгының белдерүе

ӘНКАРӘ, 22 февраль. (ТАСС). Анатоли агентлыгы, Стефани агентлыгының Кавказда совет отряды Төркия чиген үтеп чыкты дигән ялган хәбәр таратуы уңае белән 20 нче февральдә ТАСС ның совет матбугатында урнаштырылган юкка чыгаруын иглан итә.

Агентлык ТАСС ның шушы юкка чыгаруын урнаштыру белән бергә аңа түбәндәге искәрмәне өсти: Анатоли агентлыгы, Әнкарә даирәләренендә ТАСС ның бу юкка чыгаруына кушылуларын белдерә“.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

22 нче февральдә фронтта әһәмиятле бер нәрсә дә булмады.

Карелия бугазында безнең частьләр, дошманны чигенергә мәҗбүр итеп, 21 ныгытылган оборона пунктын алдылар, шулардан 15 е тимер-бетоннан ясалган артиллерия корылмалары.

Көчле буран булганлыктан авиациянең хәрәкәте күзәтү очышлары белән генә чикләнде.

Чит илләрдә

ФИНЛЯНДИЯНЕҢ ТӨНЬЯГЫНДА КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ ТУРЫНДА НОРВЕГИЯ ЖУРНАЛИСТЫ

ОСЛО, 22 февраль. (ТАСС). Норвегия матбугаты Кызыл Армиянең хәрби яктан югары дәрәҗәдә торуын һәм техникасы бик яхшы икәнлекне күрсәтә торган күп кенә мәкаләләр басып чыгарды. Норвегиянең күренекле журналисты, буржуаз „Дагбладет“ газетасының сотруднигы Аксель Кьелланд Финляндиянең төньягында совет гаскәрләренең искиткеч омтылышлы рәвештә алга баруларын яза. Каскамо районында (төньяк Финляндия) ак финнәрнең җиңелүләрен күрсәтеп, Кьелланд болай дип яза:

„Без, рус гаскәрләренең яшен тизлеге белән алга баруларын күреп, күп нәрсәләргә башкача карый башладык. Хәтта хәрби техника турында берниндн белемнәре булмаган кешеләр дә, Финляндия территориясенең миналар белән ныгытылган булуына да карамастан фантастик тизлек белән һөҗүм итеп баручы Кызыл Армиянең көченә бәя бирә алырлар.

Чыннан да, Кызыл Армия белән шаярырга ярамый.

Финнәрнең төньякта русларның коммуникацияләрен өзүләре турында хәбәрләр йөри. Финнәр анда кайдан килеп чыкканнар соң? Рус гаскәрләре үзләренең һөҗүмнәре вактында территорияне дошманнан тулысынча чистарттылар бит. Финнәр күктән төшкәннәр күрәсең!

Без финнәрнең мина кырларын күрдек. Ләкин без русларның инженерлык гаскәрләрен дә күрдек. Без рус гаскәрләренең бөтенләй җимерелгән юлны 15 минут эчендә төзәтүләрен күрдек. Бу вакытта гаскәрләрнең хәрәкәте бер генә секундка да тукталып тормады.

Сугышка бик тырышып өндәүчеләрнең күптән призыв яшеннән чыккан әфәнделәр булуы мине аз гына да гаҗәпләндерми. Әгәр хәзерге заманның танклар армиясенә каршы көрәшүнең нәрсә икәнлеген күз алдына китерә алсалар, алар башкачарак сөйләрләр иде“.

Финляндиядә совет гаскәрләренең уңышлары турында Болгария газетасы

СОФИЯ, 22 февраль. (ТАСС). Болгария матбугаты ак финнәргә каршы көрәштә совет гаскәрләренең уңышларына гаять зур игтибар бирә. „Варненски новины“ газетасы болай дип яза:

„Кызыл Армия бөтен фронтта яшен тизлегендә һөҗүм алып бара. Командованиенең алдан хәзерләнгән планнары чиктән тыш төгәл рәвештә тормышка үткәреләләр. Дошман көчсезләндерелгән. Хәзер инде ул оешкан төстә каршы торырлык хәлдә түгел. Каршылык күрсәтергә булдыра алмауларына ышанган финнәр тегендә дә, монда да коралларын калдырып качарга мәҗбүр булалар. Совет гаскәрләре моторлаштырылган частьләрнең, артиллериянең һәм авиациянең ярдәме белән һөҗүм итүне дәвам иттерәләр. Алар моңа кадәр сугышлар тарихында күренмәгән уңышларга ирешәләр: алар сугыш техникасының соңгы яңалыклары буенча корылган, ныгытылган линияләрне өзәләр. Һөҗүмнең чиктән тыш уңайсыз шартларда баруын, бу шартларның Кызыл Армиягә үзенең барлык сугыш сыйфатларын киң җәелдерергә мөмкинлек бирмәвен игтибарга алганда совет гаскәрләренең җиңүләре тагын да зуррак. Маннергейм Финляндиясе үзенең соңгы көннәрен яши“.

КӨНБАТЫШ ЕВРОПА СУГЫШЫ

ПАРИЖ, 21 февраль. Гавас агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Вогезы районында французлар артиллериясе, батареяләр өчен площадка ясаучы немец эшчеләрен тарату теләге белән ут ачкан.

Кичә Англиянең патруль караблары Германиянең су асты көймәләренә ике тапкыр атака ясаганнар. Агентлыкның әйтүенчә, соңгы 8 көндә Англия һәм Франция караблары Германиянең су асты көймәләре белән 10 тапкыр очрашканнар. Төньяк диңгездә йөк корабларын хәзер сугыш караблары гына түгел, бәлки Британиянең истребительләре дә озатып баралар. Германия самолетлары Шотландия һәм Норвегия ярлары буендагы корабларны бомбага тотканнар.

ПАРИЖ, 22 февраль. Кичә кич Парижда иглан ителгән рәсми белдерүдә „Пехотаның һәм артиллериянең җирле хәрәкәтләре булды, шулай ук авиация хәрәкәте яңадан башланды“ диелә.

Бүгенге иртәнге белдерүдә болай диелгән: „Мозельдән көнчыгышта дошманның һөҗүме кире кайтарылды. Французлар патруле немецләрнең 2 унтер-офицерын пленгә алды“.

БЕРЛИН, 22 февраль. Германия армиясенең верховный командованиесе хәбәр итә: „Германия авиациясе көнчыгыш Франция өстендә көчле разведка очышлары алып барды. Дошманның истребительләр авиациясенең каршылык күрсәтүенә дә карамастан, Германия самолетлары бернинди югалту ясамадылар. Дошман самолетларының көнбатыш фронт аркылы Германиягә очып керергә маташулары уңышсыз чыкты“.

БЕРЛИН, 21 февраль. Информация бюросының хәбәр итүенә караганда, Англиянең бер сугыш карабы Германиянең „Дюссельдорф“ пароходын буксирга тагып һәм экипажын үз бортына алып Панама каналы аркылы үткән. Пароходта Англия флагы эленгән булган.

БЕРЛИН, 21 февраль. Голландиянең ашлык төяп баручы 4.760 тонна авырлыгындагы „Тара“ пароходы Кабо де Финистерредән 160 мил ераклыкта (Испания) минага бәрелеп баткан. Экипажы коткарылган.

ЛОНДОН, 22 февраль. Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, шушы вакытка кадәр Норвегия 168.527 тонна авырлыгындагы 49 карабын югалткан. Диңгездә булган сугыш хәрәкәтләре нәтиҗәсендә Норвегиянең 327 морягы һәлак булган.

Англиянең диңгез министрлеге торпедага бәрелеп баткан „Дэринг“ эсминецында һәлак булган матросларның һәм офицерларның исемлеген иглан иткән. Исемлектә 9 офицерның һәм 147 матросның исеме күрсәтелгән.

Диңгез министре Черчилль югары палатада болай дигән: „Су асты көймәләренә каршы хәрәкәтнең нәтиҗәләре атнаданатнага үзгәреп торса да, атнасына Германиянең кимендә уртача 2 көймәсе юкка чыгарыла“. (ТАСС).

ФРАНЦИЯДӘ КОММУНИСТЛАРНЫ ЭЗӘРЛЕКЛӘҮ

БРЮССЕЛЬ, 22 февраль. (ТАСС). „Дерньер эр“ газетасының хәбәр итүенә караганда, соңгы көннәрдә Парижда полиция властьлары күп кенә тентүләр үткәргәннәр һәм 16 кешене кулга алганнар, алар „дәүләткә каршы пропаганда“ алып баруда гаепләнәләр. Кулга алынучылар барсы да тиздән Парижның хәрби трибуналына биреләчәкләр.

Депутатлар палатасы тарафыннан билгеләнгән махсус комиссия 16 коммунист депутатны хокуктан мәхрум итү турында үзенең элекке карарын раслаган. Франция сенатының махсус комиссиясе коммунист сенатор Кашенны сенаттан чыгарырга карар биргән. Комиссия утырышында Марсель Кашен компартиянең политикасын яклаган.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

КӨНЬЯК КЫТАЙДА

Гуанси провинциясенең көньяк өлешендә, Наньнин секторында 21 нче февральдә кытай гаскәрләре белән япон гаскәрләре арасында сугыш булган. Наньнин—Цинчжоу шоссесендә кытай частьләре Сяодунны алганнар.

ҮЗӘК КЫТАЙДА

Хубэй провинциясенең көньяк-көнчыгыш өлешендә, Туншань секторында кытай гаскәрләре япон гаскәрләренең атакаларын уңышлы төстә кире какканнар. Хубэй провинциясенең төньяк өлешендә, Суйчжоу секторында кытай гаскәрләре японнарның позицияләренә берничә тапкыр уңышлы атакалар ясаганнар. Аньхуэй провинциясенең көньяк-көнбатыш өлешендә, Дунлю районында шушы көннәрдә генә кытайлар артиллериясе японнарның 6 транспортына атып, аларның 4 сенә зыян китергән.

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА

„Шеньчжоужибао“ газетасының хәбәр итүенә караганда, 19 нчы февральдә кытай партизаннары Бэйпин якынында атаклы күмер үзәге булган Мыньтоугоудагы японнар гарнизонына атака ясаганнар. Кытайлар 100 дән артык япон солдатын үтереп, шәһәрне алганнар.

БАШЛАНГЫЧ ПАРТОЕШМАЛАРДА ОТЧЕТ-САЙЛАУ ЖЫЕЛЫШЛАРЫ

КОНФЕРЕНЦИЯ ИГТИБАРЫНА

(Телефон буенча үз хәбәрчебездән)

Зеленодольск шәһәрендәге башлангыч партоешмаларда отчет-сайлау жыелышлары зур күтәренкелек һәм активлык белән дәвам итә. 23 нче февральгә 17 оешмада (барлыгы 49) отчет-сайлау жыелышлары тәмамланды инде. Бу оешмаларда отчет докладлары буенча фикер алышулар вактында 107 кеше (жыелышка катнашучы коммунистларның 22 проценты) чыгып сөйләде. Фикер алышуда катнашучы иптәшләр үзләренең башлангыч партоешмалары һәм шәһәр комитеты житәкчеләрен кискен рәвештә тәнкыйтьләделәр. Аларның житәкчелек итү практикаларындагы жидди кимчелекләрен ачып салдылар.

ВКП(б) ның Шәһәр Комитеты эре промышленность предприятиеләренең эшләре белән йомшак житәкчелек иткән. Партия оешмаларын завод-фабрикалар алдында торган мөһим политик хужалык бурычларын үтәү тирәсенә житәрлек тупламаган. Нәтиҗәдә, шәһәр предприятиеләренең күп кенәсе үзләренең дәүләт планнарын үтәмиләр.

Кайбер житәкче работниклар арасында большевизмга хас булмаган семьячелек күренешләренең нык кына урын алуын әйтергә кирәк. Шәһәр партия оешмасында большевистик тәнкыйт һәм үз-үзеңне тәнкыйтьләү мактаулы урын алып житкермәгән әле.

Зеленодол, ул республикабызның эре индустриаль районнарының берсе. Шуңа карамастан, шәһәр партия оешмалары алдынгы эшчеләр һәм совет интеллигенциясе исәбенә чиктән тыш акырын үсә. Отчет чоры эчендә шәһәр партия оешмасы инженер-техник работниклар, врачлар, укытучылар исәбенә бары тик 97 кешегә үскән. Практик эштә танылган алдынгы совет хатын-кызлары исәбенә үсеш тагын да начаррак. Отчет чорында хатын-кызлардан партия сафларына бары тик 86 кеше генә алынуы әнә шул турыда сөйли, ә бөтен шәһәр предприятиеләрендәге эшчеләрнең 50—60 процентын хатын-кызлар тәшкил итәләр. Партия пропаганда һәм агитация эшләре дә бүгенге көннең таләпләренә тулы жавап бирерлек итеп оештырылмаган. ВКП(б) тарихын өйрәнү өлкәсендә жидди кимчелекләр бар. Башлангыч партоешмаларда булып узган отчет-сайлау жыелышлары моны тулы ачыкландырды.

Отчет-сайлау жыелышы тәмамланган 17 партоешманың 9 нда эш канәгатьләнерлек дип, 8 ндә канәгатьләнмәслек дип табылды.

27 нче февральдә ВКП(б) Шәһәр Комитетының IX нчы конференциясе чакырыла. Делегатлар бу конференциядә большевистик тәнкыйтьне һәм үз-үзеңне тәнкыйтьләүне кискен рәвештә жәелдерергә, шәһәр партия оешмасының эшен яхшырту өчен үзләренең конкрет тәкъдимнәрен бирергә тиешләр.

Ким Биков.

20 нче февральдә Татпромсоветта коммунистларның отчет-сайлау жыелышы булды. РӘСЕМДӘ: партбюроның отчет доклады буенча фикер алышуларда катнашучы Промснаб управляющие иптәш Г. Лядов речь сөйли.

М. Солтанов фотосы.

КОММУНИСТЛАРНЫҢ АВАНГАРДЛЫК РОЛЕ ҮСӘ

Ленин исемендәге завод партоешмасында отчет-сайлау жыелышы дүрт көн дәвам итте. Жыелышта коммунистларның активлыгы көчле булды. Доклад буенча фикер алышуларда 41 кеше катнашты.

Отчет чоры эчендә завод партоешмасы алдынгы эшчеләр, инженер-техник работниклар һәм хезмәткәрләр исәбенә 3,6 тапкыр үскән. Жирле Советларга сайлаулар вактында 200 дән артык коммунист агитатор булып эшләгән. Партия пропагандасы буенча да яхшы күрсәткечләр бар. Үзләренең идея-политик дәрәжәләрен күтәрү өстендә яхшы эшләүче коммунистлардан инженер Крайный, Фәтхеттинев, Садыйков, Федоров һәм башка күп кенә иптәшләрне күрсәтергә мөмкин. Заводта коммунистларның авангардлык роле дә үсә. Заводтагы коммунистларның күпчелеге стахановчылар һәм ударниклар.

Жыелышта чыгып сөйләүче күп кенә иптәшләр парткомның кадрларны тәрбияләү, яшь коммунистлар белән эшләү, стахановчылык хәрәкәтенә житәкчелек итү мәсьәләләренә кирәгенчә игтибар бирмәвен күрсәтеп үттеләр.

Жыелыш партком эшен канәгатьләнерлек дип тапты. Парткомның яңа составына 11 кеше сайланды.

С. Б.

Цех партоешмаларында

Серго Орджоникидзе исемендәге заводның күп кенә цех партоешмаларында отчет-сайлау жыелышлары булып үтте. Жыелышларда коммунистлар зур активлык күрсәттеләр.

Секретаре иптәш Савельев булган партоешма отчет чорында шактый эшләр башкарган. Коммунистларның политик активлыгы шактый үскән. Цехта күп кенә коммунистлар жаваплы постларга күтәрелгәннәр. Профсоюзның завод комитеты председателе яшь инженер Остапишин һәм комсомолның завод комитеты секретаре Миронов иптәшләр шушы цех коллективында тәрбияләнеп үскән коммунистлар. Афонин, Бикмөхәметов һәм Фәйзуллин иптәшләр мастер булып эшлиләр, производствода авангардлык үрнәге күрсәтәләр. Цехта агитация эшен жәелдерүгә зур игтибар бирелә. Афонин һәм Смирнов иптәшләр үзләре житәкчелек итә торган мастерскойларда политик-масса эшләрен системалы рәвештә алып баралар.

Доклад буенча чыгып сөйләгән иптәшләр карарларның үтәлешен тикшерү эше белән партбюроның житәрлек шөгыльләнмәвен, алдынгы комсомолецларны партия сафларына тарту эшен йомшак алып барганлыгын аеруча нык тәнкыйт иттеләр.

Заводның башка цехларында һәм бүлекләрендә дә отчет-сайлау жыелышлары шулай ук зур оешканлык белән үтте.

Миңнул.

НАЧАР ЖИТӘКЧЕЛЕК НӘТИЖӘСЕ

Казан Химия-Технология институты партоешмасының отчет-сайлау жыелышында партбюро секретаре иптәш Петрунин отчет докладды ясады. Ул үзенең докладында күбрәк партоешманың уңышларына тукталды, ә бюроның эшендәге житешсезлекләрне өстән-өстән генә күрсәтеп үтте. Билгеле, бу доклад коммунистларны канәгатьләндермәде.

Фикер алышуда катнашучы иптәшләр партбюроның эшендәге житешсезлекләрне, бигрәк тә бюро тарафыннан комсомол оешмасына житәкчелекнең йомшак булуын большевистик тәнкыйт уты астына алдылар. Институтта 900 комсомолец бар. Ләкин алар арасында политик-тәрбия эшләренең куелышы һич тә канәгатьләнерлек түгел. Шуның нәтиҗәсендә, аерым комсомолецлар арасында эчүчелек белән шөгыльләнү фактлары бар. Күп кенә комсомолецлар укуда артта баралар.

Партбюро һәм ВЛКСМ ның Молотов райкомы тарафыннан институт комсомол оешмасының житәкчелегенә ныгытуга жидди игтибар бирелмәгән. Ел ярым вакыт эчендә комсомол комитеты секретарьларының 6 тапкыр алышынуы шул игтибарсызлыкның нәтиҗәсе булып тора.

Бу институтта партия сафларын үстерүдә төп резерв булып комсомол оешмасы тора. Ләкин, шуңа карамастан, иң алдынгы комсомолецларны партия сафларына тарту мәсьәләсе белән бюро жидди рәвештә шөгыльләнмәгән. Отчет чорында комсомолецлардан бары тик 11 кешенең партия сафларына кабул ителүе моңа ачык мисаль була ала.

Хезмәт ияләре депутатларының жирле Советларына сайлау кампаниясе вактында партоешма гаять зур эш алып барды. Сайлау участкыларында агитатор булып 230 кеше эшләде һәм алар сайлаучылар белән 1.178 тапкыр беседалар һәм докладлар үткәрделәр. Ләкин сайлаулардан соң агитаторларның күбесе элеккеге сайлау участкыларында һәм институтта студентлар арасында агитация эшен бөтенләй туктатканнар. Фикер алышуларда катнашучылардан күп кенә иптәшләр менә шул турыда сөйләделәр һәм агитация эшен үз агымына куйган өчен партбюроны каты тәнкыйт иттеләр.

Жыелыш бюроның яңа составына политик-тәрбия, укыту педагогик эшләрне яхшырту буенча эшлекле тәкъдимнәр биреп калдырды. Партбюроның яңа составына 7 член (шуларның берсе иске составта эшләгән), Молотов район конференциясенә 8 делегат сайланды.

Ф. Ф. Малыхин.

Казан Шәһәр Комитеты инструкторы.

Пристань коммунистларының жыелышы

Казан пристане коммунистларының отчет-сайлау жыелышы зур күтәренкелек белән үтте.

Партоешма отчет чорында коллективның иң алдынгы кешеләреннән 38 кешене партиягә кабул иткән һәм 1939 нчы ел навигациясе планын арттырып үтәүгә ирешкән.

Отчет докладды буенча 22 кеше сөйләде. Сөйләүчеләр партбюро эшендәге житешсезлекләрне нык тәнкыйт иттеләр һәм киләчәк өчен эшлекле тәкъдимнәр керттеләр. Оешмада партия сафларын төп профессия эшчеләре хисабына үстерү эше йомшак тора. Эшчеләрдән 3 кенә кеше партиягә алынган. Кандидатларны тәрбияләү эше системалы рәвештә алып барылмаган. Кандидатлык сроклары күптәннән узган иптәшләр бар. Партия пропагандасының сыйфатын күтәрү, ВКП(б) тарихын үзлегеннән өйрәнүчеләргә көндәлек ярдәм, күрсәтү, комсомол оешмасына житәкчелек итү, хатын-кызларны производствога тарту кебек әһәмиятле мәсьәләләр партбюроның игтибар үзәгендә тормаганнар.

Коммунистлар ВКП(б) ның Киров райкомы һәм Шәһәр комитеты тарафыннан пристань партоешмасына житәкчелекнең житәрлек булмавын әйттеләр.

Партия жыелышы оешма эшендәге кимчелекләрне бетерү өчен конкрет юллар күрсәтте.

Ф. Исхаков.

Эш канәгатьләнерлек табылмады

Житен комбинаты янындагы башлангыч партоешманың отчет-сайлау жыелышында отчет докладды буенча сөйләүче коммунистлар партбюроның эшендәге кайбер уңышларны күрсәтү белән бергә, күп кенә житешсезлекләрне ачып салдылар.

Партбюро предприятие администрациясенең эшенә контрольлек итү хокукын тиешенчә тормышка ашырмаган. Комбинат 1938 нче һәм 1939 нчы елларны производство планын үтәмәгән. Производствода коммунистларның һәм комсомолецларның авангардлык рольләрен күтәрү өчен көрәш йомшак. Туку һәм эрләү фабрикаларында эшләүче коммунистлар арасында эш нормаларын үтәмәүчеләр бар. Алдынгыларның эш тәҗрибәләрен уртаклашу начар тора. Күп станокларда эшләүчеләрнең санын арттыру, күп профессияләрне үзләштерү хәрәкәтен жәелдерү акырын бара.

Коммунистларның политик белемнәрен күтәрү һәм партдисциплинаны ныгыту эше белән партбюро житәрлек шөгыльләнмәгән. Аерым коммунистлар тарафыннан партвзносларны вактында түләмәү, жыелышларга системалы йөрмәү, партия документларын югалту фактлары бар.

Доклад буенча фикер алышуларга 29 кеше катнашты. Жыелыш партбюроның эшен канәгатьләнмәслек дип тапты. Партбюроның яңа составына 9 член һәм район конференциясенә 27 делегат сайланды.

С. Ахметова.

ТАССР ның XX еллыгына хәзерлек

АКТИВЛЫК КҮТӘРЕЛӘ

Орденлы республикабызның XX еллыгын яңа уңышлар белән каршылау турында мехчылар чакыруы Ленин исемендәге завод коллективының производство активлыгын тагын да югары күтәрде.

Орденлы Миңнегалиев һәм Мохтаров иптәшләр аеруча яхшы эшлиләр. Алар күп станокчылар хәрәкәтен заводта башлап жибәрүче булдылар. Иптәш Миңнегалиев ике аппаратта эшли башлады һәм үзенең бригадасында эшләүче туганы, комсомолец Нурыйны социалистик ярышка чакырды. Бу ике туган үзара ярышып эшләп яхшы күрсәткечләр бирүгә ирештеләр. Хәзер алар өчәр аппаратта эшли башладылар.

Күп станокларда эшләүче хатын-кызлар саны заводта көннән-көн арта бара. Хәзерге вакытта хатын-кызлардан йөздән артык кеше элек ирләр генә башкарган эшләрне бик яхшы үтиләр. Комсомолка Питаева, Абдуллина строгальный станокта, Осипова һәм Ершова иптәшләр слесарь булып, Молчанова, Сиражеттинова иптәшләр электромонтер булып эшлиләр.

Завод коллективы ярты еллык планны Татарстанның XX еллыгы көненә үтәү өчен көрәшә.

С. Бикбулатов.

АЛГАН ЙӨКЛӘМӘЛӘРЕН НАМУС БЕЛӘН ҮТИЛӘР

Күн заводларында, шорный һәм күн-галантерея фабрикаларында Татарстанның XX еллыгын производствода яңа җиңүләр белән каршылау өчен зур хәзерлек алып барыла. Бу уңай белән эшчеләр һәм инженер-техник работниклар яңа йөкләмәләр алдылар. Хәзерге көндә бу заводларда һәм фабрикаларда күп станокларда эшләү һәм берничә профессияне үзләштерү өлкәсендә шактый яхшы нәтиҗәләргә ирешелде.

Ленин исемендәге күн заводының отделка цехы стахановчыларыннан Тихонова, Гордеева, Плаксина, Гусева һәм башка иптәшләр норманы һәр вакыт арттырып үтиләр. Шорный фабриканың кисү цехында эшләүче иптәш Шишкина һәр көнне ике норма бирә.

„Кызыл күнче" заводының отделка цехында эшләүче иптәш Хаким Сабитов бригадасы ярты еллык планны 15 нче июньдә үтәү өчен йөкләмә алды. Бригада алган йөкләмәсен намус белән үти. Январь ае планын бу бригада 160 процент, февраль аеның 15 көнлек планын 13 көндә 136,5 процент итеп үтәде.

Г. Баһау.

ТЕГҮ АРТЕЛЬЛӘРЕНДӘ

Татшвейпромсоюз артельләре Татарстан АССР ның XX еллыгын лаеклы рәвештә каршылауга хәзерләнәләр.

Артельләр 1939 нчы елны 42 миллион 300 мең сумлык (1938 нче елгы бәя белән) продукция эшләп чыгарганнар иде. Быел алар 47 миллион сумлык продукция житештерергә тиешләр. Артельләр узган елны 5 миллион 607 мең сумлык саф табыш бирделәр.

Татшвейпромсоюз Казанда һәм районнарда 26 артельне берләштерә. Аларда 4.312 член исәпләнә. Артельләр өс-баш киемнәре, аяк киемнәре һәм башка төрле киемнәр эшләп чыгаралар.

Күп кенә артельләр производство планнарын арттырып үтәп киләләр. Бөтен система буенча январь ае планы 111 процент итеп үтәлде. „Казшвейпром" артеле январь планын 129 процент, „Швеймехпром" артеле 103,5 процент итеп үтәделәр.

Артельләр Татарстан АССР ның XX еллыгы хөрмәтенә социалистик ярышны киң жәелдерделәр. Алар беренче ярты еллык планны 25 нче июньгә төгәлләргә йөкләмә алдылар.

ОЛИМПИАДАГА ХӘЗЕРЛЕК

Азнакай районында, Татарстан АССР ның XX еллыгына багышланып үткәрелә торган үзешчәнлек сәнгате олимпиадасына хәзерлек башланды. Олимпиадага хәзерләнү өчен район үзәгендә һәм колхозларда 18 комиссия оештырылды. 15 нче һәм 16 нчы мартта район үзәгендә олимпиада үткәрелә. Анда гармончылардан, жырчылардан һәм биючеләрдән 60 кеше катнашачак. Район олимпиадасында алдынгы урыннарны алган иптәшләр республика олимпиадасына жибәреләчәкләр. Олимпиадада яхшы күрсәткечләр бирүчеләр бүләкләнәчәкләр.

С. Хафизов.

Райком һәм аның эш стиле

(Үз хәбәрчебездән)

Чистай районындагы башлангыч партоешмаларда отчет-сайлау жыелышлары зур күтәренкелек белән үтте. Коммунистлар партиябезнең XVIII нче съезды һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының Май пленумы карарларын үтәү йөзеннән чыгып үткәрелгән эшләргә йомгак ясадылар, эштәге кимчелекләрне большевикларча ачтылар, киләчәк чор өчен конкрет чаралар билгеләделәр, һәм коммунизм өчен көрәштә сыналган иң яхшы большевикларны житәкче органнарга сайладылар.

ВКП(б) ның Чистай район оешмасы отчет чорында иң алдынгы кешеләр хисабына сизелерлек рәвештә үсте. 1939 нчы елны районда 478 кеше ВКП(б) сафларына кабул ителде. Коммунистларның зур күпчелеге үзләренең идея-политик дәрәжәләрен күтәрүдә, „ВКП(б) тарихының кыскача курсы"н өйрәнүдә зур тырышлык күрсәтә. Шуның нәтиҗәсе буларак, аларның производствода авангардлык рольләре дә көннән-көн үсә. Районның алдынгы яшьләре комсомол һәм партия сафларына керәләр. ВЛКСМ ның район оешмасы шушы чорда 3.102 кешегә үсте һәм иң яхшы комсомолецлардан 190 кеше ВКП(б) га кабул ителде. Районда политик-агитация эшен, массовый оборона һәм физкультура эшләрен жәелдерү буенча да шактый уңышлар бар.

Райондагы башлангыч партоешмаларның отчет-сайлау жыелышларында райкомның житәкчелегенә, аның практик эш стиленә карата да көчле тәнкыйт булды. ВКП(б) райкомы секретарьлары Аблялимов, Завьялов һәм Макрушин иптәшләр партиябезнең XVIII нче съезды карарларын һәм иптәш Сталинның күрсәтмәләрен үтәү өчен көрәшне кирәгенчә оештырмаганнар. Жанлы һәм оператив житәкчелек итү урынына Райкомда канцеляриячелек методлары яшәп килә. Моның шулай икәнлеге башлангыч партоешмаларның жыелышларында да ачык күрсәтелде. Мәсәлән, элемтә бүлеге партоешмасына үткән елны райкомнан бер кеше дә килмәгән, аның эшендәге жидди житешсезлекләрне бетерү чарасы күрелмәгән. Бу оешмадагы коммунистларның байтак өлеше үзләренең теоретик артталыкларын бетерү өстендә эшләми. „Красный Двигатель" заводы партоешмасында да шундый ук хәл. Райкомнан килгән кайбер работниклар фактларны теркәп китү белән генә чикләнгәннәр. Район газеталары редакцияләре партоешмасының эшендәге жидди кимчелекләргә дә райком игтибар итмәгән. Бу редакцияләрдә массаның сигналларына гафу ителмәслек дәрәжәдә жавапсыз карау, хәбәрче хатларын югалту фактлары урын алган. Редакцияләр аерым оешмалардагы кайбер житәкчеләрнең жинаятьләрен ача торган сигналларны бер нинди хәрәкәтсез калдыруга кадәр барып житкәннәр. Ә райком житәкчеләре бу редакцияләргә килеп тә карамаганнар. Бу фактлар райкомның шәһәр партоешмалары белән элемтәсе, аларга житәкчелеге аеруча начар торуын күрсәтәләр.

ВКП(б) сафларына кабул итү— гаять зур жаваплы эш. Ләкин райком бу өлкәдә партиябезнең XVIII нче съезды күрсәтмәләрен үтәүгә жидди әһәмият бирмәгән. Шуның нәтиҗәсендә, аерым партоешмаларда (күн заводы, Галактионов исемендәге совхоз, „Мәгариф" колхозы партоешмаларында) партиягә лаеклы булмаган, очраклы кешеләрне кабул итү фактлары булды. Райком бу ялгышны вактында төзәтмәде. Партия оешмаларының үсешен регулярләштерү, төп профессия эшчеләреннән һәм работникларыннан иң алдынгыларны партиягә алу эше белән райком тиешенчә шөгыльләнми. Моңа факт итеп районда тракторчылардан 2, комбайнчылардан 1, төп профессия эшчеләреннән 14 кенә кешене партиягә алуны күрсәтү дә житә. Мебель фабрикасы, Винзавод, такта яру заводы, Главхлеб, Шәһәр Советы һәм Наратлы авылы колхозы партоешмалары шушы көнгә кадәр ВКП(б) сафларына бер кеше дә кабул итмәгәннәр. Бу мисальләр райком житәкчеләренең ВКП(б) Өлкә Комитетының VIII нче пленумы карарларыннан кирәкле политик нәтиҗәне ясамаганлыкларын күрсәтәләр.

Партия райкомы тарафыннан комсомол оешмалары эшенә житәкчелек итү дә шулай ук начар тора. Райкомол аппараты кадрлар белән тулысынча тәэмин ителмәгән. Комсомол оешмаларында пропаганда эшенең торышы турында һәм хатын-кыз яшьләрдән тракторчылар хәзерләү турында 1939 нчы елның башында кабул ителгән карарларның үтәлеше бер тапкыр да тикшерелмәгән. Ә районда бу эшләр һич тә канәгатьләнерлек түгел. Комсомолецларның һәм союздан тыш яшьләрнең политик белемнәрен күтәрү өчен оештырылган 94 түгәрәкнең 50 сендә күптәннән инде занятиеләр булганы юк. Судноларга ремонт ясау заводы, „Борьба за урожай", „КИМ", „Победа", „Бахта", „Красный Партизан", „Дружба" һәм Андреев исемендәге колхозларда комсомолецлар арасында политик укулар аеруча начар куелган. Бу колхозлардагы партоешмаларның житәкчеләре комсомол эшенә житәкчелек итүгә бөтенләй жавапсыз карыйлар. ВЛКСМ райкомы да (секретаре иптәш Баринов) комсомол оешмаларына житәкчелек итү, производствода комсомолецларның авангардлык рольләрен күтәрү, мәктәпләрдәге комсомол һәм пионер оешмаларының эшен яхшырту мәсьәләләре белән шөгыльләнми. Мисальгә мәктәп комсомолецлары арасында отлично уку өчен көрәшнең бигрәк тә начар торуын күрсәтергә мөмкин. Шәһәрдәге икенче номерлы урта мәктәптә 150 комсомолецтан бер отличник та юк.

ВКП(б) райкомы комсомол оешмалары эшендәге житешсезлекләрне бетерү мәсьәләсен принципиаль югарылыкка куеп тикшерергә һаман да вакыт „тапмый".

Районның хужалык һәм культура эшләренә житәкчелек итү буенча да партия райкомының жидди кимчелекләре бар. Язгы чәчүгә хәзерлекнең һәм социалистик ярышны жәелдерүгә житәкчелекнең канәгатьләнерлек булмавы да моны ачык күрсәтә.

Партиянең район конференциясе, ВКП(б) ның XVIII нче съезды тарафыннан куелган зур бурычларны үтәү йөзеннән карап, райкомның эшендәге жидди кимчелекләрне большевистик тәнкыйт уты астына алырга, партиянең район житәкчелегенә нык сыналган һәм иң яхшы коммунистларны сайлауны тәэмин итәргә тиеш.

К. Исламов.

БЕРЕНЧЕ ЙОМГАКЛАР

КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ. (Телефон буенча үз хәбәрчебездән). Районда 16 башлангыч партоешмада отчет-сайлау жыелышлары тәмам булды. Отчет докладлары буенча фикер алышулар вактында коммунистларның 56 проценты катнашты. Алар партоешма житәкчеләренең эшләрендәге жидди кимчелекләрне ачып салдылар һәм каты тәнкыйт иттеләр.

Зверосовхоз янындагы башлангыч партоешмада коммунистлар оешманың кимчелекләрен нык тәнкыйтьләделәр. Бу оешма коммунистларның идея-политик белемнәрен күтәрү белән житәрлек шөгыльләнмәгән. Производство планын үтәү өчен көрәш нык жәелдерелмәгән. Язгы чәчүгә хәзерлек канәгатьләнерлек түгел. Партоешманың эше канәгатьләнмәслек дип табылды.

Отчет-сайлау жыелышлары тәмам булган 16 партоешманың 2 сендә генә яңа секретарьлар сайланды. Бу, түбәнге партактивның үсүен, житәкчелек итү эшен аларның яхшы үзләштерүләрен һәм коммунистлар алдында авторитетлары ныгуын күрсәтә.

Н. Мәжитов.

АКТАНЫШ МТС ы КОЛЛЕКТИВЫНА

МОСКВА, 21 февраль. Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенең Татарстан АССР павильоны коллективы Актаныш МТС ы коллективын хөкүмәтнең бөек бүләген—Ленин ордены алуы уңае белән кайнар рәвештә котлый. Колхоз төзелешен тагын да ныгытуда куәтле этәргеч булу ролен көчәйтүен, үз алдына куелган бурычларны киләчәктә дә намус белән үтәвен һәм якын елларда барлык колхозларда да Сталинчыл югары уңыш алуга ирешүен телибез.

Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенең Татарстан АССР павильоны коллективы.

Татарстан Җир Эшләре Халык Комиссариаты Актаныш МТС ы работниклары һәм белгечләре коллективын МТС ның бөек бүләк—Ленин ордены белән бүләкләнүе белән чын күңелдән котлый. Сезнең МТС берничә еллар инде машина-трактор паркының эшләп чыгаручанлыгын күтәрү өчен һәм югары иген уңышы өчен көрәштә социалистик ярышның инициаторы булып килә. Бу бөек бүләк сезне эшкә тагын да ныграк рухландырыр, машина-тракторлар паркының эшләп чыгарышын тагын да күтәрү өчен, Сталинчыл югары уңыш алу өчен көрәшкә туплар, орденлы республикабызның йөзпотчылары хәрәкәтендә сезнең алгы сафта булуыгызга көчле этәргеч булыр, дип ышанабыз.

Татарстан Җир Эшләре Халык Комиссарының урынбасары *Гадельшин.*

Партбюро секретаре *Галимов.*

ЧИКСЕЗ ЗУР ШАТЛЫК

АКТАНЫШ. (Телефон буенча). Актаныш МТС ының хөкүмәт тарафыннан Ленин ордены белән бүләкләнү хәбәрен районның барлык хезмәт ияләре чиксез зур шатлык белән каршы алдылар. Шушы уңай белән МТС коллективының, район үзәгендә эшләүче хезмәткәрләр һәм колхозчылар катнашы белән, митингысы булып үтте. Митингта 300 кеше катнашты. Митингны район советы башкарма комитетының председателе иптәш Кутлин ачты.

Ул үзенең сүзендә: бу бөек бүләкне яулап алу белән быел Сталинчыл иген уңышы алуга ирешү, социалистик терлекчелекне үстерү, колхозларны тагын да ныгыту өчен көрәштә районның барлык хезмәт ияләре алдында тагын да җаваплырак бурычлар торганлыгын әйтте.

Митингта МТС ның өлкән механигы Музеев, тракторчы хатын-кызлар отряды бригадиры Кадимова һ. б. иптәшләр чыгып сөйләделәр.

Митингта сөекле юлбашчыбыз иптәш Сталин һәм хөкүмәтебез башлыгы иптәш Молотов исменә хат кабул ителде.

Коллектив бу бөек бүләк өчен партиябезгә, хөкүмәтебезгә һәм сөекле юлбашчыбыз иптәш Сталинга тирән рәхмәт белдерә. Бу бөек ышанычны аклау өчен тракторчылар, комбайнчылар һәм барлык колхозчылар социалистик ярышны һәм стахановчылык хәрәкәтен тагын да җәелдерү һәм быелгы кыр эшләрен үрнәк рәвештә үткәрүгә ирешүе турында вагдә бирәләр.

Газизов.

МТС директорының политик эшләр буенча урынбасары.

СОВХОЗ ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ХӘЗЕР

Алабуга районындагы промсовхоз эшчеләре йөзпотчыларның Бөтенсоюз ярышына кушылып конкрет йөкләмәләр алганнар иде. Алар үз йөкләмәләрен үтәү өчен ныклы көрәш алып баралар. Тракторларга һәм тагылма инвентарьларга ремонт ясау срогыннан алда тәгәлләнде. 11 тракторга, 6 чәчкечкә, 4 культиваторга, 13 сабанга һ.б. ремонт ясалды. Ремонтта эшләүчеләрдән Юшков, Асадуллин һәм Хванский иптәшләр норманы көн саен 200 процент үтәп бардылар.

Совхозда кышкы агротехника чаралары планын үтәү эше дә яхшы бара. 370 гектар мәйданда кар тоту үткәрелде, басуга 100 тонна тирес чыгарылды, 21 тонна минерал ашлама хәзерләнде. Чәчү орлыклары җитәрлек хәзерләнгән.

С. Сафиуллин.

БУРЫЧКА 1.272 ЦЕНТНЕР ОРЛЫК БИРДЕЛӘР

ПУЧЫ, 23 февраль. (Телефон буенча). Чәчү орлыклары үзләреннән арта торган колхозлар чәчү орлыклары җитәрлек булмаган колхозларга бурычка орлык бирәләр. Бу эш көннән-көн җәелә. Ленин исмендәге колхоз „Беренче Май“ колхозына 250 центнер бодай һәм „Октябрьнең 12 еллыгы“ колхозына 277 центнер солы бирде. „Чиялек“ һәм „Бүләк Бул“ колхозлары шул ук „Беренче Май“ колхозына 236 центнер солы һәм 52 центнер борчак, „Удар“ колхозы „Октябрьнең 12 еллыгы“ колхозына 137 центнер солы, „Ирекле“, „Коминтерн“ һәм „Маркс“ колхозлары Сталин исмендәге колхозга 220 центнер бодай һәм 100 центнер солы бирделәр.

В. Г. Герасимов.

Калинин район җир бүлеге мөдире.

МТС ларда тракторларга ремонт ясауның барышы турында Татарстан Җир Эшләре Халык Комиссариатының сводкасы

1940 нчы елның 20 нче февраленә

Көзге-кышкы ремонт планына карата процентларда

МТС лар	Үтәлеш	МТС лар	Үтәлеш	МТС лар	Үтәлеш
Нөркәй	100,0	Исәнбай	65,8	Дөбъяз	48,1
Тымытык	100,0	Тәтеш	65,4	Ромадан	47,7
Теләче	100,0	Норлат	65,2	Әхмәмәт	47,7
Маткавыш	100,0	Бондюг	65,1	Чиябаш	47,1
Кама Тамагы	100,0	Балык Бистәсе	64,9	Буа	46,5
Актаныш	100,0	Тәкәнеш	64,3	Чыбыклы	45,9
Мөслим	100,0	Этнә	64,0	Мөслим (Чистай)	45,8
Янил	100,0	Буденный	63,6	Алексеевский	45,5
Чалпы	100,0	Алабуга	63,4	Алькин	45,2
Алга	100,0	Чүпрәле	61,0	Поповка	44,9
Кадрәк	100,0	Каргалы	60,7	Питрәч	44,6
Тирсә	100,0	Макыл	60,8	Иске Писмән	44,4
Т. Тамак	100,0	Беренче Май	60,0	Яна Чишмә	44,4
Әлмәт	98,0	Акташ	59,3	Салман	44,4
Юртыш	96,0	Трехозерский	58,0	Морт	42,6
Минзәлә	88,1	Калинин	57,4	Әлки	42,0
Иске Чишмә	86,4	Б. Матак	57,4	Рождественский	41,5
Иши	82,4	Чишмә	56,7	Кичү	40,7
Тархан	81,4	Зирекле	56,1	Кызыл Йолдыз	40,0
Зур Поляна	81,0	Кузнечиха	55,6	Заинский	3 ,2
Черемуховский	79,6	Кукмара	55,3	Димитров	36,4
Сарман	79,3	Кошкино	55,0	Үзәк	34,6
Саба	75,0	Мәйдан	54,8	Тельман	34,0
Азин	74,4	Кәкре Елга	54,5	Зоя	33,3
Столбище	72,7	Кызыл Юл	54,2	Мөрәле	30,6
Дәүләки	72,5	Ютазы	53,7	Чокалы	29,1
Мамадыш	72,2	Чүрибураш	53,5	Карамалы	28,6
Аксубай	71,4	Юдино	53,2	Константиновка	28,1
Чаллы	70,8	Иске Тимошкино	51,2	Татходяш	21,3
Мәлки	70,8	Сокольский	51,1		
Чистай	70,0	Биектау	50,9		
Зур Кләре	67,7	Арча	50,0	МТС лар буенча барлыгы	61,1
Шөгер	68,6	Баулы	50,0		
Куйбышев	68,0	Бөгелмә	50,0	1940 нчы елның 1нче январена	56, 7
Октябрь	67,9	Тат. Ялтан	50,0		
Балтач	66,0	Биләр	48,9	1939 нчы елның 20 нче февраленә	63,4
Кызыл Чапчак	66,0	Кузайкино	48,1		

ХАЛЫКАРА КОММУНИСТИК ХАТЫН-КЫЗЛАР КӨНЕ—8 НЧЕ МАРТ АЛДЫННАН

Мине комбинат үстерде

Әле дә булса хәтеремдә. 1911 нче елның язы иде. Мин әнием эшли торган фабриканың эрләү цехына өйрәнчек булып кердем. Капиталист Алафузовның ерткыч мастерлары кулы астында эшкә өйрәнү минем өчен җиңел булмады. Бик күп кимсетүләр, мыскыллаулар күрдем. Чиктән тыш авыр шартларда 12 шәр сәгать эшләсәм дә, айлык хезмәт хакым 3 сумнан артмады.

Бары тик Бөек Октябрь Социалистик революциясе генә минем һәм минем кебек миллионлаган хезмәт ияләренең изелүләренә чик куйды.

Элекке кечкенә, ярым җимерек фабрика хәзер танымаслык булып үзгәрде. Аның цехлары бөтенләй яңа баштан корылып, катлаулы станоклар белән җиһазландырылдылар. Фабрика Союз күләмендә әһәмияте булган комбинат булып әверелде.

Житен комбинатында эшләгән 29 ел вакыт минем өчен зур мәктәп булды. Мин тукучылык эшенең катлаулы процессларын үзләштереп, бай тәҗрибә тупладым. Үземнең техник белемемне арттыра бардым, эш культурасын нык үзләштердем. Үземне политик яктан хәзерләп, партия члены дигән мактаулы исемне алу бәхетенә ирештем.

1939 нчы елда туку цехын „Нартроп“ системасындагы яңа һәм гаять катлаулы туку машиналары белән җиһазладылар. Бу машиналарда эшләү техникасын үзләштереп, шул ук елның октябрь аенда башта ике станокта, аннан соң дүрт станокта эшләүгә күчтем. Элек бер эшче бер машинада эшләп сменага 25 метр киндер тукыса, хәзер мин 4 машинада эшләп, 130—140 метр киндер тукыйм.

Мин үземнең тәҗрибәмне башкаларга күчерү буенча тырышып эшлим. Соңгы елларда гына да 20 гә якын кешене тукучылык эшенә өйрәтеп чыгардым. Мин өйрәткән иптәш Саматова хәзер берьюлы 4 туку машинасында эшләп, норманы һәр ай саен арттырып үти. Зарипова, Хәлиуллина һәм башка күп кенә иптәшләр икешәр машинада эшлиләр.

Шулай да, күп станокта эшләүчеләргә комбинат җитәкчеләренең булышлыгы җитәрлек түгел әле. Күп станокчыларга эшләү өчен шартлар тудырылмаган. Кагыйдә буларак, шүреләрне станоклар янына ярдәмче эшчеләр ташырга тиеш булса да, еш кына үзебезгә ташырга туры килә. Моның өчен машиналарны туктатып, икенче катка менәргә кирәк. Бу бик күп вакытны ала һәм машиналарның эшләп чыгаруын киметә. Күп вакытта озатмалар җитешми. Озатмаларның сыйфаты начар булганлыктан, җеп еш кына өзелә. Шуның аркасында машиналарны эштән туктатырга туры килә.

Без үз эшебездә тагын да яхшырак эшләрбез. Быелгы Халыкара Коммунистик хатын-кызлар көне—8 нче Мартны производствода хезмәт җитештерүчәнлегенең тагын да югарырак күрсәткечләре белән каршыларбыз.

Таифә Галәветтинова.

Туку цехы стахановчысы.

В. И. Ленин исмендәге җитен комбинатының алдынгы хатын-кызлары (сулдан уңга): берьюлы 4 станокта эшләүче, хөкүмәтебез тарафыннан „Аеруча хезмәт күрсәткән өчен“ медале белән бүләкләнгән А. Е. Иванова, комбинатта 40 нчы елын эшләүче ватерщица С. И. Горина, ФЗУ мәктәбенең инструкторы-тукучы М. Рәхмәтуллина һәм тарау цехының смена мастеры А. П. Столярова иптәшләр.

И. Галиев фотосы.

ЭШ МЕТОДЫМНЫ БАШКАЛАРГА КҮЧЕРӘМ

1935 нче елның март ае. Мин колхоздан килеп, җитен комбинатының туку цехына эшкә кердем. Мине өйрәнчек итеп алдылар. Ләкин бу чор озакка бармады. Нак 8 көн эшләгәч тә, мине машинада эшләргә куйдылар. Комбинатка кереп эшли башлавыма өч ай дигәндә инде мин дәүләт техника сынавын отличнога тапшырып, берьюлы ике станокта эшли башладым.

1938 нче елда комбинат, Москва, Смоленск һәм Вязники шәһәрләрендәге туку фабрикаларына алдынгы стахановчыларның экскурсиясен оештырды. Бу экскурсиядә миң дә катнаштым. Без Москвада иң бай техника белән коралланган туку фабрикасында булдык. Смоленск эшчеләренең эш методларын өйрәндек. Вязники шәһәрендәге ефәк тукый торган станокларда үзебез эшләп карадык. Вязники туку фабрикаларында инде шул вакытта ук берьюлы дүрт туку машинасында эшләүчеләр бар иде. Без аларның эшләү методларын аеруча кызыксыну белән өйрәндек.

Экскурсиядән кайткач, мин үзем эшли торган цехтагы эшчеләрне җыеп, экскурсиядә күргәннәрне сөйләдем. Вязники тукучыларының эшләү методлары белән таныштырдым һәм дүрт станокта эшләүгә күчү өчен хәзерлек эшләре алып бара башладым. Бу эш белән кызыксынучылар күп булды. 1939 нчы елның январь аенда мин һәм тагын 5 тукучы комбинатта беренче булып, берьюлы дүрт машинада эшли башладык һәм эштә яхшы нәтиҗәләр бирдек.

Хәзер бризент туку машиналарында эшләүчеләрдән 28 кеше берьюлы дүртәр машинада, 12 кеше өчәр машинада, ә калганнары барсы да икешәр машинада эшлиләр.

Күптән түгел мине стахановчылык методы инструкторы итеп күтәрделәр. Миңа эш процессын яхшылап үзләштереп җиткермәгән һәм моңа кадәр көнлек норма үтәлешен 50—60 проценттан арттырмаган 11 кеше беркетелде. Мин башта аларның ничек эшләүләре белән, машиналарның төзеклеге белән таныштым. Аннан соң үзем станок янына басып эшләп күрсәттем һәм аларга ничек эшләргә кирәклекне өйрәттем. Аларның ялгышлыкларын күрсәтә бардым. Берничә көн эчендә бу иптәшләр үзләренең эшләрендә кискен борылыш ясадылар. Смирнова, Борисова, Якушина һәм Петушкова иптәшләр хәзер көнлек норманы арттырып үтиләр.

Мин үземә беркетелгән бу 11 кешене 8 нче март көненә кадәр алдынгы стахановчылар итү йөкләмәсен алдым.

Е. И. Малова.

„Аеруча хезмәт күрсәткән өчен“ медале белән бүләкләнүче.

Эш шартлары тудырылсын

Безнең бригада иптәш Хәмидуллина бригадасы белән ярыша. Ике арада төзелгән ярыш договорының үтәлешен системалы рәвештә тикшерәбез. Безнең бригада планны сан һәм сыйфат ягыннан үтәүдә алда бара. Айлык план 110 процентан ким үтәлми. Бригадада барлыгы 26 кеше эшли һәм алар хәзер барсы да диярлек стахановча эшләүне үзләштерделәр.

Орденлы республикабызның данлыклы XX еллык бәйрәменә бүләк итеп, ярты еллык планны 25 нче июньгә 110 процент итеп үтәү йөкләмәсен алдык һәм бу йөкләмәне эш белән ныгытабыз. Халыкара Коммунистик хатын-кызлар көне—8 нче Март бәйрәмен февраль ае планын 25 нче февральгә үтәп каршылырбыз. Початкы машинасында эшләүче атаклылардан Фәйзуллина, Хөсәенова һәм Мөхәмәтҗанова иптәшләр ярышта алдынгылыкны тоталар. Алар үзләренә бирелгән заданиеләрне арттырып үтәү белән бергә, бай тәҗрибәләрен артта калучыларга күчерү эшен, тәҗрибәләр белән уртаклашу эшен оештырдылар.

Ләкин безнең эштә тоткарлык ясый торган кимчелекләр дә юк түгел. Товар җитешми. Моның өчен фабриканың коры эрләү бүлеге гаепле. Чөнки ул безгә һәр смена саен диярлек 200—250 килограмм товар биреп җиткерми. Бу зур кимчелек бетерелгәндә, без тагын да яхшырак эшли алыр идек.

Е. Тимофеева.

Эрләү фабрикасының початкы бүлеге бригадиры.

В. И. Ленин исмендәге җитен комбинатының алдынгы хатын-кызлары (сулдан уңга): эрләү цехының бригадиры А. И. Иванова, берьюлы ике фрезер станогында эшләүче Е. Н. Жирнова, тарау цехының гекельщицасы Н. Нигмәтҗанова һәм 4 станокта эшләүче, тукучы Т. Галәветтинова иптәшләр.

И. Галиев фотосы.

Һәр вакыт алдынгы сафта булырбыз

Житен комбинатында мин 28 ел эшлим. Техниканы яхшы үзләштергәч мине югары квалификация таләп ителә торган процесста машинистка итеп күтәрделәр. Мин берничә профессияне үзләштердем. Элек өч кеше башкара торган эшне бер үзем башкаруга ирештем. Демидова, Колпатчикова, Мехеева, Тарасова иптәшләр бу эштә миннән үрнәк алдылар. Алар элек ирләр генә башкара ала торган процесста эшлиләр һәм производство заданиесен бер ярым—ике тапкыр арттырып үтиләр. Минем белән бергә Демидова һәм Колпатчикова иптәшләр дә күп профессияләрне үзләштерүдәге үзләренең бай тәҗрибәләрен башкалар белән уртаклашалар.

Соңгы вакытта миңа тагын да җаваплырак эш йөкләтелде. Мине цехның смена мастеры итеп күтәрделәр.

Сменаны алдынгылар сафына чыгару өчен күп көч куярга туры килде. Моның нәтиҗәсе яхшы. Смена айлык планны 110 проценттан ким үтәми.

Орденлы республикабызның XX еллык бәйрәме якынлаша. Безнең сменаның эшчеләр һәм инженер-техник работниклар коллективы ярты еллык планны 25 нче июньгә 110 процент үтәү йөкләмәсен алды һәм иптәш Захаров сменасын социалистик ярышка чакырды.

Житен комбинатында иң күпчелек хатын-кызлар. Алар Халыкара Коммунистик хатын-кызлар көне—8 нче Мартны зур күтәренкелек, производство активлыгы белән каршы алу өчен көрәшәләр. Безнең смена хатын-кызлары февраль ае планын срогыннан алда үтәү өчен, югары сыйфатлы продукция эшләп чыгару өчен социалистик ярыш байрагын югары күтәрәләр.

А. Столярова.

Ленин исмендәге житен комбинатының тарау цехы смена мастеры.

АГРОТЕХНИКА УКУЛАРЫН БЕЗ НИЧЕК ОЕШТЫРДЫК

Үткән елларда бездә агротехника укуларын оештыру буенча зур гына кимчелекләр булды. Түгәрәк члennарының даими составы булмады. Бу хәл укуларның сыйфатын түбәнәйтте. Нәтиҗәдә, түгәрәк членнарының 50 проценты гына программа материалларын үзләштерә алдылар. Быел агротехника укуларын оештыруда бу кимчелек бетерелде. Түгәрәк членнарының даими составы булдырылды.

Түгәрәккә, беренче чиратта, авыл советы һәм колхоз председательләре, бригадирлар, звено башлыклары тартылды. Агротехника белемен өйрәнү буенча районда 56 түгәрәк бар. Бу түгәрәкләрдә 1.145 колхозчы укый.

Түгәрәк занятиеләренә 6 агроном, колхоз тәҗрибәчеләреннән, агротехниклардан 27 кеше һәм алдынгы бригадирлардан 23 кеше җитәкчелек итә. Түгәрәкләрдә практик эш башлаганчы бу иптәшләр район курс-киңәшмәсендә булдылар. Бу курс-киңәшмәдә программа мәсьәләләре, укыту методлары, күргәзмә җиһазлар куллану һәм башка мәсьәләләр тикшерелде. Аннан соң һәр айның 6—18—30 нчы көннәрендә барлык түгәрәк җитәкчеләре өчен район үзәгендә консультация үткәрелә. Бу консультацияләрдә алдагы занятиенең темасы һәм тема өстендә эшләү юллары өйрәнелә. Бу чараны үткәрү занятиеләрнең сыйфатын яхшыртуга нык ярдәм итә.

Без темаларны колхоз производствосының бүгенге сорауларына карата сайлап алдык. Беренче занятиедә „Үсемлекләр өчен су режимы“ дигән теманы үттек. Бу теманы иң элек үтүнең максаты түгәрәктә үтелгән теорияне практика белән бәйләп алып баруда иде. Бу вакытта колхоз басуларында кар тоту эшләрен нык җәеп җибәрү кирәк иде. Түгәрәктә катнашучылар җитәкчелегендә колхозларда 6.500 гектар мәйданда кар тоту чаралары үткәрелде.

Икенче занятие „Чәчү орлыклары“ дигән темада булды. Бу занятиене үткәннән соң түгәрәк членнары чәчү орлыклары хәзерләү һәм аларны чистарту эшләренә практик рәвештә катнаштылар. Алар җитәкчелегендә 12 көн эчендә 20 мең центнер чәчү орлыгы чистартылды.

Өченче занятие ашламалар турында булды. Бу тема да уңайлы вакытка туры китереп сайланды. Бу занятиене үтү белән колхозларда басуга тирес чыгару, көл, кош тизәге һәм фекаль ашламалар җыю эшләре массовый төс алды. Шуннан соң январь аенда колхозларда басуга 100 мең йөктән артык тирес чыгарылды. 1.200 центнер көл һәм 500 центнер кош тизәге җыелды.

Январь ае керү белән колхозларда еллык производство планнары төзү, бригадаларга еллык заданиеләр җиткерү һәм бригадалар эчендә даими звенолар оештыру, аларга планнар җиткерү кебек гаять әһәмиятле эшләр башланды. Ефремовчы звенолар оештыру, аларның эшләрен планлаштыру безнең өчен яңа нәрсә. Бу мәсьәләләрне дөрес хәл итү һәм бу эшкә түгәрәк членнарын актив катнаштыру теләге белән январь аенда „Хезмәтне оештыру һәм колхоз производствосын планлаштыру“ дигән теманы үттек.

Шулай итеп, агротехника белемен өйрәнү занятиеләрен без колхоз производствосында үткәрелә торган чаралар белән бәйләп алып барабыз. Һәм моны киләчәктә дә шулай дәвам иттерәчәкбез. Алдагы темаларны язгы чәчүне агротехника кагыйдәләренә төгәл туры китереп үткәрү һәм игеннәрне тәрбияләү мәсьәләләренә карата билгеләдек.

Эшне шулай оештыру түгәрәк членнарының теорияне практика белән бәйләп алып баруларына, үтелгән материалларны яхшы үзләштерүләренә һәм колхозларда үткәрелә торган теге яки бу эшне уңышлы башкаруга нык ярдәм итә. Моның шулай икәнең безнең тәҗрибә ачык күрсәтте. Булачак занятиенең темасы түгәрәк членнарына алдан әйтелеп куела, алар колхозда яки үз бригадаларында бу тема буенча практик эшнең торышы белән танышып киләләр. Мәсәлән, Куйбышев исмендәге колхоз члены иптәш Әхметшин „чәчү орлыклары“ дигән теманы үтү занятиесенә колхоздагы чәчү орлыкларын тикшереп, аларны категорияләргә бүлеп алып килде. Мондый тәҗрибәләр башка колхозларда да үткәрелә.

Г. Яхин.

Тымытык район җир бүлегенең баш агрономы.

Чит илләрдә

ЯПОНИЯ—АМЕРИКА МӨНАСӘБӘТЛӘРЕ

ТОКИО, 22 февраль. (ТАСС). „Джапан таймс" газетасының хәбәр итүенә караганда, 19 нчы февральдә пресс-конференциядә чит ил эшләре министрлеге вәкиле речь белән чыккан. Япония—Америка мөнасәбәтләренә кагылып ул: „АКШ тан Япониягә экспорт товарларына эмбарго кертү турында сөйләшүләр дәвам иткәндә Япония—Америка мөнасәбәтләре өстендә кара болытлар торыр" дигән. Аннары вәкил, Япония матбугатының Япониягә чыгарыла торган товарларга АКШ та эмбарго кертү турындагы мәсьәләне чиктән тыш җидди эш дип санавын белдергән. Япониянең эшлекле даирәләре дә шушы ук фикерне уртаклашалар. Шуннан соң министрлек вәкиле болай дигән: „Мин Япония матбугатының белдерүләре белән риза түгел, бу белдерүләрдә Япония хөкүмәте АКШ белән теләктәшлек политикасыннан баш тартырга һәм үзенең бәйсезлек политикасын үткәрергә тиеш дип күрсәтелә".

Соңгы көннәрдә Япония матбугаты тугыз дәүләт договорын юкка чыгару өчен тагын кампания башлаган. Шуның белән бергә, Япония Ерак Көнчыгышта АКШ белән хисаплашмаска тиеш дигән таләп куела.

„Асахи" газетасы баш мәкаләсендә, Япониягә каршы эмбарго кертү турындагы мәсьәләне Америка сенатында тикшерүне кичектерү Япония—Америка мөнасәбәтләре гомумән яхшырды дигән сүз түгел, дип күрсәтә. Газетаның сүзләренә караганда, эмбарго кертүне кичектерү һәм Уэллеснең Европага баруы арасында кайбер элемтә бар. „Уэллес Муссолини һәм Чиано белән очрашу өчен Италия пароходында турыдан-туры Италиягә киткән. Аның сәяхәтенең аеруча әһәмияте бар".

Япония парламенты депутаты Сайтоның белдерүе

ТОКИО, 22 февраль. (ТАСС). 2 нче февральдә Япония парламентының түбәнге палатасында Минсейто партиясе члены депутат Сайто Такао Кытай мәсьәләсендә Япония хөкүмәтенең һәм хәрби даирәләрнең юлын кискен рәвештә тәнкыйтьләгән иде. Сайтоның рече парламент сессиясенең стенограммасыннан алып ташланган иде.

„Хоци" газетасы Сайто белән булган интервьюне басып чыгарды. Сайто 23 нче февральдә парламентның дисциплина комитеты алдына басарга тиеш. Сайто болай дип белдергән: „Бөтен бәлә шуннан гыйбарәт ки, бар нәрсә дә сер итеп тотыла. Минем йөрәгем илебез турында тынычсызлану белән тулган. Минем речемнең тулы текстын халык алдында игълан итү өчен миңа мөмкинлек бирегез. Ил бер нәрсә дә белми. Парламентның членнары—начар иптәшләр. Алар илнең хәле турында бик начар беләләр. Бөтен Япониядә чын дәүләт эшлеклесе булырлык кеше юк. Мине җәзаларга тырышучы кешеләргә карау көлке. Мин күренекле даирәләрдән депутатлык полномочиемне үземнән алып ташларга киңәшләр алам, ләкин мин моны бер вакытта да эшләмәм. Әгәр дә мин депутатлык полномочиемне алып ташларлык дәрәҗәдә шундый зур ялгышлык эшләгәнмен икән, ул чагында мин үз-үземне үтерергә тиешмен".

ЯКЫН КӨНЧЫГЫШТА АНГЛИЯНЕҢ ҺӘМ ФРАНЦИЯНЕҢ КАЗЫНУЛАРЫ

Якын Көнчыгышта турыдан-туры яки читләтә Англия һәм Франция империализмы власте астында булган гарәб илләре өчен хәзерге вакытта Көнбатыш Европада бара торган сугышның гаять зур әһәмияте бар.

Якын Көнчыгышка Англия һәм Франция гаять зур әһәмият бирәләр. Төньяк Африкада һәм бигрәк тә Азиядә Англиянең һәм Франциянең өстенлеген саклап калу өчен җир шарының бу өлешенең стратегик яктан нинди зур урын тотуы һәр кемгә маглүм. Англия—Франция сугыш блогы Якын Көнчыгышны Германиянең көньяк флангына куркыныч тудыру өчен плацдарм дип карый. Сугыш уты кабызучыларның Балкан илләренә басым ясаулары шушы планның бер кисәге. Англиянең һәм Франциянең әһәмиятле юллары Якын Көнчыгыш аркылы үтә. Англия тарафыннан ярым колонияләргә әверелдерелгән гарәб илләре аркылы Африка белән Һиндстан арасында Сувәеш каналына бәйсез булган коры юл салыну—1914—18 нче еллардагы бөтен дөнья сугышыннан соң таланган байлыкны бүлүнең әһәмиятле нәтиҗәләреннән берсе.

Англия һәм Франция империалистлары Якын Көнчыгыш илләрендә иң рәхимсез колониаль изү системасы керттеләр. Англия—Франция хакимлеге империализмга каршы хәрәкәттә катнашучыларны җәзалауларга һәм атуларга нигезләнгән. Шуңа күрә Англия һәм Франция газеталарының „демократия өчен" көрәштә, ягъни Германиягә каршы сугышта гарәб илләре союзникларны яклаячаклар дигән ялган хәбәрләре бигрәк тә магнәсез булып күренәләр.

1914—18 нче еллардагы бөтен дөнья сугышында гарәбләрне „Төрек солтаннары ерткычлыгыннан азат булыйк" дигән лозунг белән алдадылар. Хәзер „Берлин ерткычлыгына каршы көрәш" дигән яңа лозунг уйлап чыгардылар. Шушы тупас хәйлә белән Лондон һәм Париж изелгән гарәбләр массасының ачуын Германиягә каршы юнәлдерергә маташалар.

Якын Көнчыгыш илләре хәзер сугышның һәлакәтле йогынтысын сизәләр. Импорт товарларының нык җитешмәве сизелә. Кыйммәтчелек үсә. Чимал җитешмәү аркасында уртача, вак һәм күп санлы кустарьчылык-һөнәрчелек предприятиеләре эштән туктыйлар. Гарәб илләренең крестьяннарен налоглар белән буалар. Бары тик алып сатучылар һәм спекулянтлар гына үзләрен яхшы хис итәләр.

Соңгы вакытта бөтен дөнья матбугатында Якын Көнчыгышта гаскәрләрнең, бигрәк тә Франция гаскәрләренең туплануы турында хәбәрләр тулып ята. Җирле халыкны „доброволецлар" сыйфатында союзникларның армияләренә туплыйлар. Хәзергә чама белән 200—300 мең кешедән тора торган бу гаскәрләрнең нәрсәгә билгеләнүләре Англия матбугаты хәбәрләреннән ачык күренә. „Дейли телеграф энд Морнинг Пост" газетасы шушы елның январь башында болай дип язды: „Мисыр, Фәләстыйн һәм Сурия үзләренә куркынычсызлыкны җирле көчләр белән тәэмин итәчәкләр. Француз гаскәрләренә килгәндә исә, алар барсы да ярдәмгә килә торган өстәмә көчләр белән берлектә көнчыгыш фронт өчен билгеләнәләр". Якын Көнчыгышта Англия—Франция блогының сугыш хәзерлекләренең магнәсе әнә шундый.

Сугышта катнашкан өчен һәм территорияләрен плацдарм сыйфатында файдаланган өчен Англия һәм Франция гарәб халыкларына нәрсә вәгдә итәләр соң? Бәлки тагын гарәбләр дәүләте төзү лозунгысы куела торгандыр һәм гарәб илләренә бәйсезлек бирү турында вәгдәләр бирелә торгандыр? Юк, бу лозунглар хәзер куркыныч дип саналалар һәм Англия—Франция империалистлары алар белән шаярырга батырчылык итмәсләр.

Америкада чыга торган „Эйша" журналының ноябрь номерында урнаштырылган мәкалә бу яктан караганда бик кызыклы. Державаларның хәзерге империалистик сугыштагы планнарын тикшереп, мәкаләнең авторы Якын Көнчыгышта территорияләрне бүлү мөмкинлеге турындагы нәтиҗәгә килә. Автор гарәб илләрен яңадан талауга хәзерләнүне акларга тырыша.

Мәкаләдә болай диелә:

„5—10 тапкыр артыграк халык яши ала торган һәм бөтен дөньяның экономик һәм культура юллары үзәгендә урнашкан территориядә ни өчен 12—15 миллион гарәбләр генә торырга тиеш? Бу аңлашылмый. Әгәр тулысынча үзләштерелсә, Гыйракның үзендә генә дә хәзер бөтен Якын Көнчыгышта яшәгәнгә караганда 2 тапкыр артыграк халык яши алачак. Халыкның күп туплануыннан хәтта гарәбләр дә шактый файда итәчәкләр".

Америкада бетерелеп бара торган индеецлар өчен билгеләнгән кебек, гарәбләр өчен дә „резервацияләр" (махсус иң начар районнар) билгеләү—авторның фикеренчә иң реаль һәм уңайлы комбинация әнә шушы. Англия—Франция империализмы гарәб халыклары өчен, ихтимал, әнә шундый язмыш хәзерли торгандыр.

Ләкин Якын Көнчыгышта үзләренең хәрби-стратегик һәм басып алу планнарын тормышка ашыруда Англия һәм Франция алдында зур бер киртә тора. Ул—Якын Көнчыгыш илләрендәге хезмәт ияләренең каршылык күрсәтүләре. Сурия, Фәләстыйн, Трансиордания, Гыйрак халыклары гарәб илләрен империалистик сугышка тартырга маташуларга каршы кискен төстә чыгалар. Төркиядә чыга торган „Җөмһүрият" газетасының хәбәр итүенчә бөтен Суриядә сугышка каршы таратыла торган прокламацияләрдә бу ачык күренә. Прокламацияләрнең берсендә: „Без бары тик үзебезнең бәйсезлегебез өчен генә, Сүриянең азатлыгы өчен генә сугышачакбыз һәм үләчәкбез"—диелә. Башка гарәб илләрендә дә халыкның настроениесе шундый. Якын Көнчыгышта Англиянең һәм Франциянең империалистик планнарын тормышка ашыру империализмга каршы үсеп бара торган хәрәкәткә очрый.

В. Васильев.

„ИРЕК" ОПЕРАСЫ ТУРЫНДА

АВТОРДАН

„Качкын" операсы халыкның үз азатлыгы өчен көрәш идеясен чагылдыру нигезендә төзелгән иде. „Ирек" операсы әнә шул идеянең логик дәвамы, тәгәлләнүе булып тора диергә мөмкин.

„Качкын" операсындагы шикелле үк, бу операда да баш рольне масса—халык башкара. Ләкин бирегә инде масса стихия төсендә хәрәкәт итми, бәлки фронттан кайткан большевик солдат йөзендә коммунистлар—большевиклар партиясе җитәкчелегендә хәрәкәт итә һәм Россия халыкларын эксплоатациядән азат иткән Бөек Социалистик Октябрь революциясенә килә.

Минем алда, операны массага аңлаешлы итеп язу, аның дөрес булуын, халыкчыл булуын тәэмин итү бурычы торды. Татарның күп сандагы чын халык мелодияләрен операга механик рәвештә генә кертү ул операның халыкчыл булуы дигән сүз түгел. Опера үзендәге моңнарның характеры буенча, татар халык мелодиясенә якын торган интонациясе буенча халыкчыл булырга тиеш. Шул ук вакытта бу, татарның чын халык көйләреннән баш тартырга кирәк дигән сүз дә түгел. Өченче акттагы бию бөтенләй диярлек татар халык биюе „Әпипә"гә корылган һәм, ниһаять, дүртенче актта Шамиль татар халык җыры „Кара урман"ны җырлый.

„Ирек" операсы өстендә эшләгән хәлдә мин, шулай ук, татар музыкасын стильләштерергә дә тырышмадым, чөнки бу эш композиторны үзенең эшендә чикләгән булыр иде. Рус музыка культурасы һәм совет операсы традицияләре белән барып, мин музыка теленең барлык средстволарыннан кыю рәвештә файдаландым.

Кагыйдә буларак, опера өстендә композитор эшенең тәгәлләнүе әле ул эшнең беренче стадиясе булып кына тора. Опера халыкка күрсәтелү өчен дирижер һәм режиссерлар кулына күчкәч, аның икенче һәм хәл итүче стадиясе башлана.

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Савелий Соломонович Бергольц „Качкын" операсын сәхнәгә кую буенча кыен эшне гаять яхшы башкарып чыккан иде. Аның талантлы җитәкчелегендә, опера коллективының бердәм тырышлык күрсәтүе белән, „Ирек" операсының да уңышлы башкарылуына ышанасы килә.

Нәҗип Җиһанов.

Татарстан АССР ның атказанган сәнгать эшлеклесе, „Ирек" операсының авторы.

МУЗЫКА КУЛЬТУРАСЫ ФРОНТЫНДА ЯҢА ҖИҢҮ

Татар Дәүләт Опера театры композитор Нәҗип Җиһановның яңа операсын куярга керешә.

Җиһанов үзенең беренче операсы „Качкын" белән үк талантлы композитор икәнлеген күрсәткән иде. Яңа опера аның иҗад үсешендә тагын да алга китү этапы булып тора. Җиһановның бу яңа әсәре Татарстанның музыка культурасы фронтында, һичшиксез, яңа җиңү булачак.

Интонациясенең яңалыгы, музыкасының эчтәлекле һәм гади булуы аркасында „Ирек" операсы совет тыңлаучыларына якын һәм аңлаешлы булачак. Музыканың операда бөтен настроениеләрне гәүдәләндерүе кирәк. Җиһанов „Ирек" операсында моңарга тулысынча ирешкән.

„Ирек" операсы, татарча оригиналь опера булганы хәлдә, үзенең югары художество дәрәҗәсе белән татар хезмәт массасы тарафыннан да, шулай ук башка милләт хезмәт ияләре тарафыннан да зур кызыксыну белән тыңланырлык опера.

Операның зур өлешендә Җиһанов күп кенә музыкаль образларны: Бибисараны, Хәятны һәм башкаларны күрсәтүдә уңышлы юллар тапкан.

Дирижер буларак, „Ирек" операсын сәхнәдә гәүдәләндергәндә, мин операның социаль идеясен аеруча ачык итеп күрсәтүне һәм, шулай ук, музыкаль образларны гади һәм иң ачык итеп бирүне төп бурычым дип санadым.

С. Бергольц.

Татарстан АССР ның атказанган сәнгать эшлеклесе.

„ИРЕК" НЕҢ ЛИБРЕТТОСЫ ТУРЫНДА БЕРНИЧӘ СҮЗ

Казанның киң катлау хезмәт массасы 24 нче февральдә, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе талантлы композитор Нәҗип Җиһановның „Ирек" операсын тыңлый башлый.

Бу операның либреттосын язу минем өлешкә туры килде. Бөек Социалистик Октябрь революциясе алдыннан крестьяннарнең революцион хәрәкәте фонында халыкның бәхетле тормышы өчен армый-талмый көрәш алып баручы халык геройлары образларын тамашачы күз алдыннан үткәрү, аларны җыр-музыка моңнары белән бизәп гәүдәләндерү—либреттоны язудан максат итеп әнә шул бурыч алынды.

Бу зур теманы кечкенә бер опера либреттосына сыйдырып, тамашачыны тулысынча канәгатьләндерү, әлбәттә, кыен эш. Кимчелекләре булыр. Операны караучы масса, аерым алганда, театр һәм әдәбият өлкәсендә эшләүчеләр безне төзәтерләр, дип уйлыйбыз.

З. Сафин.

„Ирек" либреттосы авторы.

ПОСТАНОВКАЧЫДАН

Н. Җиһановның „Ирек" операсы өстендә эшләвемне опера сәхнәсе белән беренче җидди танышуым итеп саныйм.

„Ирек" нең музыка материалы гаять бай һәм тәмам эшләнгән. Бу хәл, үз алдында бердәм идеягә буйсынган һәм ачык гәүдәләнгән музыкаль фикер барлыкны хис итеп көннән-көн зур ышаныч белән эшләргә мөмкинлек бирде.

Яңа операны мәхәббәт белән кабул иткән яшь коллектив практик эш өстендә үзенең үсешен дәвам иттерү өчен яңа материал алды.

„Ирек" операсы халыкның данлыклы геройлыгы чорларыннан берсен чагылдыру бурычын куя. Шуңа күрә, анда крестьяннәр массасының ирек алуга карата аерым омтылышларын гына түгел, бәлки азатлыкка нинди юллар белән килүе процессын күрсәтү дөрес булыр дип уйланды.

Операның композициясендә дә халыкка хас булган героик стильне күрергә мөмкин. 7 картинадан торган бу яңа операның 5 картинасы массавый-хор картиналарыннан гыйбарәт.

Ш. Сарымсаков.

„Ирек" операсын сәхнәгә куючы режиссер.

„ИРЕК" ОПЕРАСЫНЫҢ ОФОРМЛЕНИЕСЕ ТУРЫНДА

Татар сәнгате тарихында икенче опера спектаклен тудыру эшендә катнашу бурычын—бу мактаулы бурычны үз өстемә алганнан соң, мин опера оформлениесен хәзерләү буенча гадәттәге методны бераз үзгәртергә карар бирдем. Шушы теләк белән мин, спектакльне куючы режиссер белән берлектә, Татарстан районнарына барып кайттым. Операның оформлениесе урындагы конкрет обстановканы күрү, өйрәнү нәтиҗәсендә барлыкка килде.

Миңа тәкъдим ителгән сәхнә кай вакытларда хәтта драма театрының элементар таләпләренә дә җавап бирми. Постановка өлеше гаять катлаулы булган опера театры өчен аның никадәр чикләнгән булуы турында сөйләп тә торасы юк.

Музыкаль спектакльдә оформлениене күп төрле төсләр белән хәл итү мәсьәләсе гаять зур роль уйнаганлыкны белгән хәлдә, мин һәрбер картинаны рәсем сәнгате ягыннан нык эшләүгә аеруча игътибар бирдем, оформлениенең һәм костюмнарның маглүм бер матурлык белән күрсәтелүләрен теләк итеп куйдым.

...оңарга никадәр дәрәҗәдә ирешә алуымны тамашачылар күрсәтерләр.

М. Шипулин.

Татар Дәүләт Опера театрының художнигы.

ЧАҢГЫ ЧАБЫШЫ

Балтач урта мәктәбенең 10 нчы классында укучы допризывниклар Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгы хөрмәтенә Балтач—Казан маршруты белән чаңгы чабышы үткәрделәр. Запастагы лейтенант иптәш Хөснетдинов җитәкчелегендә оештырылган чаңгычылар командасы 23 нче февральдә иртә белән Казанга килеп җитте. Алар Балтач белән Казан арасындагы 110 километр дистанцияне 16 сәгатьтә үткәннәр. Чаңгычылар юлда килгән вакытта Бимәр, Түбән Мәтәскә һәм Чыпчык авыллары колхозларында данлыклы бәйрәм турында беседалар үткәргәннәр.

Чабышта катнашучылар Татарстан Осоавиахимының Үзәк Советы председателе иптәш Щербак тарафыннан кабул ителделәр. Алар Балтач районында оборона эшләренең уңышлары турында рапорт тапшырдылар.

МАССОВЫЙ ОБОРОНА БӘЙРӘМЕ

Бүген Ирек мәйданында Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенең һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгына багышланган зур массовый оборона бәйрәме үткәрелә.

Бәйрәм программасында физкультурникларның противогазлар кигән хәлдә чаңгыларда кроссы, мото-чаңгы чабышы, командаларның граната ярышлары, шәһәр допризывникларының хәрби-химия ярышлары, Ворошиловчы кавалеристларның чыгышы һәм башкалар бар.

Бәйрәм көндез 10 сәгатьтә башлана.

СТАДИОННАРДА

„Динамо" стадионында „Спартак" җәмгыяте Үзәк Советының хоккей кубогы өчен Казан һәм Чиләбе командалары арасында очрашу була. Уен көндез 2 сәгатьтә башлана.

* * *

„Локомотив" стадионында Татарстанның Спорт-Физкультура Комитеты призы өчен шәһәр хоккейчыларының очрашулары үткәрелә. „Спартак" (икенче командасы) хоккейчылары „Советлар канаты" командасы белән, „Наука" командасы Казан Химия-Технология институты командасы белән уйныйлар.

Умарта кортлары үрчетү

Совет хөкүмәте умарта кортлары үрчетүгә зур әһәмият бирә.

1939 нчы елда Татарстан колхозларындагы умартачылык фермаларында 235.000 данәдән артык, колхозчыларның үз хуҗалыкларында 91.144 данә умарта бар иде. Быел умарта кортлары семьяләрен тагын да арттыру чаралары күрелә. Колхозларда яңадан 23 ферма төзелә. Шуның белән колхозлардагы умартачылык фермаларының саны 3.720 гә җитә. Барлык фермаларда умарта кортлары семьяләре 247.139 данәгә җиткерелә.

Колхозчыларның үз хуҗалыкларындагы умарта кортлары семьяләрен 101.696 данәгә җиткерү чаралары билгеләнде. Колхозлар һәм колхозчылар өчен 41.133 данә рамлы умарталар хәзерләнәчәк.

27 нче февраль, кич 6 сәгатьтә Укытучылар йортында (Островский урамы, 10) Казан шәһәре Бауман районының XIV нче партконференциясе чакырыла.
ВКП(б) ның Бауман райкомы.

Җаваплы редактор
һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

Дәүләт Банкысы Татарстан Республика конторасының Шәһәр идарәсе барлык клиентларына белдерә:

1940 нчы елның II нче кварталында хезмәт хакы түләү һәм башка расходлар өчен кирәк булачак хәзер акча сумасына заявкалар шушы ел 1 нче мартка кадәр генә алына.

Барлык оешмаларның һәм учреждениеләрнең хәзердән үк Банк Конторасы Шәһәр идарәсенең тиешле оператив группаларыннан заявка бланкларын алулары һәм аларны тутырып, күрсәтелгән сроктан соңга калмыйча Банк Шәһәр идарәсенең кассовый план группасына бирүләре сорала.

Дәүләт Банкысы Татконторасының Шәһәр идарәсе.

25—2—1

Горпромторгның 24 нче магазинында
(Киров урамы, 58-5)
йөк ташу кирәк-яраклары һәм агач товарлары сатыла
Товарлар учреждениеләргә, оешмаларга һәм предприятиеләргә хәзер акчасыз расчетлар буенча җибәрелә.
261—1.

Гражданнар игътибарына!
Бауман район страхование инспекциясе
гомерне һәм йорт җиһазларын коллектив һәм индивидуаль страхованиеләү эшләре үткәрә.
Гомерне һәм йорт җиһазларын страхованиеләү өчен—Чернышевский урамы, 9 адресы буенча килергә яисә 38—27 телефоны буенча страхование агентын чакыртырга.
Бауман районы страхинспекциясе.
328—3—1

Татарстан АССР Совнаркомы янындагы Автотранспорт идарәсенең
ТОВАР-СКЛАД КОНТОРАСЫ
тимер юл станциясендә һәм пристаньдә клиентларның йөкләрен алу һәм озату буенча экспедицион, ә тимер юл станциясе һәм пристань складларыннан йөкләрне төяү яисә складларга бушату, шулай ук йөкләрне шәһәр складларында саклау буенча
клиентларына хезмәт күрсәтә
Югарыда күрсәтелгән эшләрнең йөкләрне күчерү белән бәйләнешле булганнарын контора үз транспорты белән үти.
Шартлары турында сөйләшү өчен түбәндәге адрес буенча килергә: Казан, Нариман урамы, 40. Телефоннар: 43—82 һәм 3—96.
280—3—1

КИРӘК:

Казан Дәүләт Медицина институты студентларын урнаштыру өчен
БҮЛМӘЛӘР һәм почмак урыннар КИРӘК
Университет урамы, 13. Телефон 7—92.
267—2—2

Казан 2 нче төзәтү-хезмәт колониясенә БУХГАЛТЕРЛАР, ӨЛКӘН БУХГАЛТЕРЛАР, КАРТОТЕКАЧЫЛАР, ХИСАПЧЫЛАР, ҖИТЕШТЕРҮ БҮЛЕГЕ РАБОТНИКЛАРЫ, ИНЖЕНЕР-ТЕХНОЛОГЛАР һәм АГАЧ МАТЕРИАЛЛАР СКЛАДЫ ӨЧЕН МӨДИР. Хезмәт хакы килешү буенча. Кызыл Армия бистәсе, 1 һәм 5 нче маршрут трамвайларының Петров паркы янындагы туктавы. Телефон № 19—22.
345—3—1

Татарстан АССР НКВД ның хезмәт колонияләре бүлегенә ПРОИЗВОДСТВОЧЫ ИНЖЕНЕР, БАШ БУХГАЛТЕРЛАР, ТОВАР ҖИТЕШТЕРҮ БУЕНЧА ЭШЛӘҮЧЕЛӘР һәм ХӘРБИЛӘШТЕРЕЛГӘН ОХРАННИКЛАР. Казан, Чернышевский урамы, 12/20, кадрлар бүлеге. 215—3—2

Казан Психатрия больницасына даими эшкә ХИСАПЧЫЛАР, МАШИНИСТКАЛАР, ОХРАННИКЛАР, ДИПЛОМЛЫ КОЧЕГАРЛАР, СЛЕСАРЬ-МЕХАНИКА ЭШЛӘРЕ БУЕНЧА НОРМАЛАУЧЫЛАР һәм ТӨЗЕЛЕШ ЭШЛӘРЕ БУЕНЧА ӨЛКӘН БУХГАЛТЕР. Казан, Ершов кыры, 5 (3, 6 һәм 8 нче маршрут трамвайлары). Телефоннар: 4—27 һәм 32. 337—3—1

„ГЛАВПАРФЮМЕР" ның ТАТАРСТАН КОНТОРАСЫНА (Лобачевский урамы, 3) БАШ БУХГАЛТЕР УРЫНБАСАРЫ.
350—3—1

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
24 нче февральдә көндез 12 сәгатьтә
МАСКАРАД
Кич премьера
ЛЕНИН
Талоннар: көндез 22, кич 108.
Коллектив рәвештә килү өчен заявкалар алына.
Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана.
Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 7 сәгат 30 минутка кадәр кассада сатыла.

28 нче февраль, кич 7 сәгатьтә Тире-Венера Авырулары клиникасы аудиториясендә Казан Дәүләт Мединституты гыйлми советының ачык утырышы чакырыла һәм медицина фәннәре кандидаты дигән гыйлми дәрәҗә алу өчен түбәндәге темаларда халык алдында
ДИССЕРТАЦИЯ ЯКЛАУ үткәрелә:
1. Врач Г. А. Гутман. Тема: „Рак авырулы аналыктагы нәсел бизләренең эчке секреция эшләрен өйрәнүгә карата кайбер маглүматлар".
Рәсми оппонентлар: профессор И. Ф. Козлов һәм профессор П. В. Маненков.
2. Врач В. Н. Марков—Осоргин. Тема: „Кымызның микроорганизмнары".
Рәсми оппонентлар: профессор Б. И. Вольтер һәм Р. Р. Гельтцер.
Диссертация материаллары белән Медицина Фәнни Җәмгыятьләре советы китапханәсендә танышырга мөмкин.
354—1

Казан Дәүләт Медицина институтының тире авырулары клиникасындагы
косметика һәм гигиена КАБИНЕТЫНДА
(Толстой урамы, 4, телефон 33—79)
сыткыларны, бетчәләрне, сипкелләрне, тиредәге миң, сөял кебек төрле кимчелекләрне дәвалау, биткә массаж ясау, тирене тәрбияләү, чәчне дәвалау һәм доцентлар тарафыннан консультацияләр бирү эшләре алып барыла.
Кабул итү—түләүле, гомуми ял көннәреннән башка һәр көн көндез 4 сәгатьтән кич 7 гә кадәр.
2427—1

Татарстан АССР Совнаркомы янындагы Автоуправление
АВТО МӘКТӘБЕ
производстводан аерып һәм аермыйча укытып газогенераторчы һәм бензинчы III нче класс шоферлар хәзерләү группасына, шулай ук III нче класс шоферлардан II һәм I нче класс шоферлар хәзерләү группаларына
УКУЧЫЛАР АЛА
Укучылар учреждение, оешма яисә предприятиеләрдән бирелгән командировкалар буенча, шулай ук индивидуаль тәртиптә дә алына. Казан, Свердлов урамы, 40. Телефон 9—86.
260—2—1

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
25 һәм 26 нчы февральдә
БУЛАК АРТЫ „РЕСПУБЛИКАСЫ"
Талоннар: 123 һәм 124.
Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 9 га кадәр ачык.
ТДАТ.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген һәм һәр көн Москваның Ленин орденлы Дәүләт циркы артистларының гастроле
СТРАТОС—3
Номерлар орденлы артист БАСТ җитәкчелегендә башкарыла. Аэропланда үлем әлмәкләре һәм башка күп номерлар.
РСФСР ның атказанган һәм орденлы артисты **М. ЗОЛЛО** гастрольләре дәвам итә.
Бүген көндез 12 сәгатьтә
ЗУР ЦИРК УЕНЫ
Уен кич 8 дә башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 1 гә һәм кич 5 тән 9 га кадәр ачык.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ДҮРТЕНЧЕ ПЕРИСКОП
„УНИОН" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ЧАПАЕВ
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ" 6, 8 һәм 10 да	ДҮРТЕНЧЕ ПЕРИСКОП
„Колхозник" 4, 6, 8 һәм 10 да.	КЫЗЫЛ АРМИЯ
„ЧАТКЫ" 6, 8, 9-30 да.	ИУДА
„ПИОНЕР" 11, 1, 2, 4, 6, 8, 10 да.	ПАТРИОТ Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„РОТ-ФРОНТ" 4, 6, 8, 10 да.	БАЛТЫКЧЫЛАР
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	СОҢГЫ ТӨН

Пассажирлар йөртү пароходларында даими рәвештә эшләү өчен
фельдшерлар һәм фельдшерицалар чакырыла
Хезмәт хакы 1935 нче ел, 4 нче март законы нигезендә түләнә һәм 30 проценттан 70 процентка кадәр күләмдә навигацион өстәмә хезмәт хакы бирелә.
Гариза бирү һәм белешмәләр алу өчен адрес: Горький шәһәре, Нагорный тыкрыгы, 3. Горький портының Дәүләт Санитария инспекциясе.
355—1

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 253 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА. ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 758.